ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ им. ЛЕНИНА БИБЛИОТЕКИ АТССР г. Казань
...KITAPXANƏSE TÞP KITAP SAQLAV BYLEGE

ЯКШӘМБЕ
3 МАРТ
1940 ел
№ 51 (5851)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ: Казан, Матбугат йорты. ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—73, типография 36—60, бухгалтерия һәм игъланнар бүлеге 2—19.

ВКП(б) ның Казан шәһәр конференциясе

Казан шәһәрендәге башлангыч партоешмаларда һәм район оешмаларында отчет-сайлау җыелышлары тәмам булды. ВКП(б) ның район конференцияләре идея-политик яктан югары дәрәҗәдә үттеләр. Большевистик сафларның тагын да ныгуы, коммунистларның политик активлыклары үсүе, Сталинчыл Үзәк Комитет тирәсенә тагын да тыгызрак тупланганлык, бу җыелышларда һәм конференцияләрдә бөтен тулылыгы белән чагылды.

Коммунистлар башлангыч оешмаларның һәм район оешмаларының эшләренә тирән анализ ясадылар, отчет чоры эчендә ирешелгән уңышларны тулы рәвештә күрсәтү белән бергә, көндәлек эштә яшәп килә торган кимчелекләрне һәм аларны тудыручы кешеләрне каты тәнкыйть иттеләр. Отчет-сайлау җыелышлары партия эчендәге демократиянең тагын да үсүен, массовый-политик эшнең тагын да көчәюен күрсәтә торган көчле демонстрация булды.

ВКП(б) ның Казан шәһәр оешмасы орденлы республика большевикларының алдынгы отряды булып тора. Казан шәһәре большевиклары моны яхшы беләләр һәм бу алдынгылыкны эш белән аклау өчен җидди көрәш алып баралар. Моның шулай икәнлеген район конференцияләренең йомгаклары бик ачык күрсәтә.

— ВКП(б) райкомының политик линиясен дөрес дип, практик эшен канәгатьләнерлек дип табарга—Казан шәһәрендәге райкомнарга партия конференцияләре тарафыннан бирелгән политик бәя әнә шундый.

ВКП(б) ның Казан шәһәр оешмасы үзенең сафларын ике йөзлеләрдән тазарту буенча, тотанаксыз элементлардан, очраклы кешеләрдән арындыру буенча өзлексез эш алып барды. Бу чор эчендә шәһәрнең алдынгы кешеләреннән меңнәрчә стахановчылар, ударниклар, инженер-техник работниклар, фән һәм сәнгать эшлеклеләре ВКП(б) сафларына кабул ителделәр. Отчет чоры эчендә партиянең шәһәр оешмасы үзенең сафларына барлыгы 5.739 кеше кабул итте.

Отчет чоры эчендә ирешелгән уңышларның иң әһәмиятлеләреннән берсе итеп тагын шуны күрсәтергә кирәк: партия оешмаларының күпчелеге хуҗалык бурычларын партия-политик эш белән дөрес бәйләп алып бара башладылар, кадрлар сайлап алуның һәм аларны җитәкче эшләргә күтәрүнең Сталинчыл принципын үзләштерделәр. Бу исә промышленность предприятиеләренең күпчелегендә производство планнарының тулы һәм арттырылып үтәлүен тәэмин итте, күп санлы яңа, яшь кадрларның тизлек белән үсүләрен тәэмин итте.

„ВКП(б) тарихының кыскача курсы" басылып чыгу һәм шул уңай белән ВКП(б) Үзәк Комитеты карары — кадрларыбызны марксизм-ленинизм фәне белән коралландыруда хәл иткеч роль уйнады һәм уйный. Партияле һәм партиясез кадрларның теоретик артталыкларын бетерү буенча партиянең Казан шәһәр оешмасы һәм аерым алганда Шәһәр Комитеты шактый зур эш үткәрде. „Кыскача курс"ны үзлекләреннән өйрәнүче иптәшләргә ярдәм итү максаты белән шәһәр күләмендә һәм шәһәр районнарында йөзләрчә лекцияләр укылды, консультацияләр бирелде, докладлар ясалды. Хәзерге көндә шәһәрдә утыз меңнән артык кеше „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н өйрәнү өстендә, марксизм-ленинизм фәнен үзләштерү өстендә эшли.

Партиянең шәһәр оешмасы, Казан шәһәре большевиклары үзләренең V нче конференцияләренә әнә шундый зур уңышлар белән, политик яктан тагын да чыныккан, идея ягыннан үскән хәлдә, партиябез штабы тирәсенә һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин тирәсенә тагын да тыгызрак тупланган хәлдә киләләр. Ләкин бу, оешманың эшендә, аерым алганда ВКП(б) Шәһәр Комитетының практик эшендә җитешсезлекләр юк дигән сүз түгел әле. Партиянең район конференцияләрендә чыгып сөйләгән делегатлар ВКП(б) Шәһәр Комитетында шактый зур кимчелекләр яшәп килүен күрсәттеләр һәм ул җитешсезлекләр шәһәр конференциясендә бөтен тулылыгы белән ачып салынырга тиешләр.

ВКП(б) Шәһәр Комитетының практик эшендә төп җитешсезлекләрнең берсе—ул, партиянең шәһәр райкомнарына һәм аларның бүлекләренә дифференциаль җитәкчелекнең йомшак булуында, Шәһәр Комитетының бүлекләре тарафыннан кадрлар белән эшләүнең начар куелуында, партия, хуҗалык оешмаларының эшләренә системалы рәвештә анализ ясап тормауда һәм, ниһаять, шәһәр хуҗалыгы үсешенә оператив җитәкчелекне тәэмин итмәүдә. Промышленность төзелеше ягыннан гаять кызу темплар белән үскән һәм хәзер дә үсүендә дәвам итә торган Казан шәһәренең культура - көнкүреш төзелеше ягыннан шактый артка калып килүе, барыннан да элек, әнә шуннан—шәһәр хуҗалыгы үсешенә конкрет һәм оператив җитәкчелекнең җитәрлек булмавыннан килә.

Дөрес, шәһәр хуҗалыгын төзекләндерү һәм үстерү буенча соңгы елларда Шәһәр Комитеты инициативасы белән күп кенә эшләр башкарылды. Ләкин алар шәһәр хезмәт ияләренең сорауларын канәгатьләндерерлек булудан ерак торалар әле. Шәһәр хуҗалыгы тирәсендә яшелчә базасы булдыру турында да шуны ук әйтергә кирәк. Бу мәсьәләгә карата бик күп карарлар булды, ләкин нәтиҗә аз күренде. Шулай булгач, партиянең Шәһәр Комитетында хуҗалык мәсьәләләрен политик эшләр белән бергә бәйләп алып бару яхшы куелган дип буламы? Юк, яхшы куелган дип булмый әле. Конференция делегатлары бу кимчелекләргә җидди игтибар бирергә тиешләр.

Партиянең шәһәр конференциясе идея-политик яктан тагын да югарырак дәрәҗәдә үтәргә, большевистик тәнкыйть һәм үзенне тәнкыйтьләү бөтен көченә яңгырарга тиеш. Отчет чоры эчендә ирешелгән уңышларны тулы рәвештә күрсәтергә, аларны яулап алу өчен барган көрәшнең бай тәҗрибәләрен уртаклашырга, көндәлек эштә яшәп килә торган кимчелекләрне большевистик кыюлык белән ачып салырга һәм аларны бетерү юлларын күрсәтергә кирәк. ВКП(б) ның Казан шәһәр конференциясе делегатлары бу мәсьәләләргә зур әһәмият бирерләр һәм алда торган бөек бурычларны эшлекле рәвештә тикшерерләр, культура-хуҗалык төзелешендә, партия-политик эштә яңа уңышларга ирешү өчен практик чаралар билгеләрләр.

АНГЛИЯ БЕЛӘН СССР АРАСЫНДА КУЛЬТУРА ЭЛЕМТӘСЕ ҖӘМГЫЯТЕНДӘ КАБУЛ ИТҮ

ЛОНДОН, 1 март. (ТАСС). Шушы көннәрдә генә Англия белән СССР арасында культура элемтәсе җәмгыяте Лондонда еллык кабул итү ясады. Кабул итү зур күтәренкелек белән үтте. Быел кабул итүдә үткән елгы шундый ук кабул итүдәгегә караганда күбрәк кунаклар катнашты. Анда Тревельян председательлек итте.

Кабул итүдә катнашучылар арасында Англиянең атаклы юристы, түбәнге палата члены Притт, Англиянең күренекле кооператив эшлеклесе Ривс, епископ Кентерберийский, Англиянең атаклы композиторы һәм дирижеры Алан Буш, Англиянең музыка дөньясының күп кенә башка вәкилләре, Кембридж университетының рус теле укытучысы доктор Хилл һәм башкалар катнаштылар.

Ораторлар Англия һәм совет халыклары арасында дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыруның кирәклеген күрсәттеләр.

ВКП(б) ның КАЗАН ШӘҺӘР ОЕШМАСЫНЫҢ V нче КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ДЕЛЕГАТЛАРЫ ИГТИБАРЫНА

Партиянең шәһәр күләмендәге V нче конференциясе бүген, 18 сәгатьтә Менжинский исемендәге клуб бинасында ачыла.

Делегатлык билетлары иртән 9 сәгатьтән 15 сәгатькә кадәр ВКП(б) ның Шәһәр Комитеты бинасында 19 нчы бүлмәдә бирелә. (Астрономический урам, 15/19).

Оештыру комиссиясе.

Чит илләрдә

Карелия бугазында Кызыл Армиянең уңышлары турында чит ил матбугаты

НЬЮ-ЙОРК 29 февраль. (ТАСС). Карелия бугазында Кызыл Армия частьләренең һөҗүменә анализ ясап, „Нью-Йорк пост" газетасының хәрби күзәтүчесе Пратт, Кызыл Армия „Карелия бугазындагы һөҗүме белән үзенең максатына инде ирешә диярлек мөмкин" дип яза. Праттның язуына караганда, географик шартлардан файдалану русларның шактый осталыгын күрсәтә. Финнәр бик авыр хәлдә торалар.

Американың „Лайф" журналы, Кызыл Армиянең һөҗүме чит ил хәбәрчеләренең Кызыл Армия турында үзләренең фикерләрен яңадан карарга мәҗбүр итә, дип яза. Журналның язуына караганда, Кызыл Армиянең беренче классы кораллары, бигрәк тә беренче классы пулеметлары һәм танклары бар. Совет гаскәрләренең мораль хәле яхшы.

ЛОНДОН, 29 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Хельсинкидагы хәбәрчесенең белдерүенә караганда, финнәрнең Койвистодагы яр буе батареяләрен югалтуларын монда җидди удар дип карыйлар, чөнки бу батареяләрнең уты русларның сугыш корабларына ярга якынаерга мөмкинлек бирми иде һәм Маннергейм линиясе артына десант төшерергә тырышуга комачаулык итә иде.

БЕРЛИН, 29 февраль. (ТАСС). „Национал цейтунг" газетасы хәбәрчесе Хельсинкидан Финляндиядә совет гаскәрләренең зур уңышлары турында хәбәр итә. Хәбәрче болай дип яза:

„Алынган хәбәрләргә караганда, Карелия бугазында финнәрнең хәле көннән-көн начарлана бара. Тайпале районында Кызыл Армиянең һөҗүме аеруча уңышлы булды. Монда финнәргә ныклы удар ясалды. Бу районда берничә көн буена дәвам иткән көчле буран совет гаскәрләренең һөҗүмен аз гына да киметә алмады. Карелия бугазында фин гаскәрләренең хәле шул кадәр ышанычсыз ки, бу турыда хәтта финнәрнең рәсми сводкаларында да әйтелә башлады".

СОФИЯ, 29 февраль. (ТАСС). Кичәге газеталар үзләренең белдерүләрендә Койвисто атавын совет гаскәрләренең алуы стратегик яктан гаять әһәмиятле дип язалар. „Зора" газетасы, Койвисто атавының алынуы белән Карелия бугазында һөҗүмнең яңа фазасы башлана дип яза. Газетаның язуынча: „Выборгны алу бу ныгытмаларны алуның турыдан-туры нәтиҗәсе булачак".

„Утро" газетасы болай дип яза:

„Бөтен чит ил матбугаты совет гаскәрләренең Койвисто атавын алулары турында бик нык фикер йөртә. Сугыш хәрәкәтләренең киләчәктәге барышы өчен моның хәл иткеч әһәмияте булачагы күрсәтелә, чөнки Койвисто крепосты Маннергейм оборонасы линиясенең иң әһәмиятле өлеше иде".

Бөтен Болгария матбугаты Финляндиядә җиңүчән һөҗүм алып баручы Кызыл Армиянең гаять зур куәтен күрсәтеп үтә. „Утро" газетасы, совет гаскәрләренең моңарчы һич булмаган һәм күренмәгән тизлек белән һөҗүм итүләрен яза. „Заря" газетасы Кызыл Армиянең куәтен һәм техника белән яхшы тәэмин ителгәнлеген күрсәтеп, укучыларны Маннергейм линиясе белән тулы итеп таныштыра. Шул ук вакытта газета бу ныгытмаларны „Англиянең, Франциянең һәм Германиянең тәҗрибәле сугыш белгечләре тарафыннан төзелгәнлеген һәм ныклык ягыннан Мажино һәм Зигфрид линияләреннән һич тә калышмавын" аеруча күрсәтеп үтә.

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 28 февраль. Информация бюросының хәбәр итүенә караганда, „Англия һәм Шотландия ярлары өстендә разведка ясаган 2 Германия самолеты үз базаларына кайтмаганнар. Самолетларның берсенең экипажын Англиянең сакчылык корабы коткарган. Бу экипаж составының бер члены яраланган".

БРЮССЕЛЬ, 29 февраль. Франциядә чыга торган „Журналь" газетасының 28 нче февральдәге хәрби күзәтүендә болай диелә: „Фронтта әһәмиятле бер нәрсә дә булмады. Немец патрульләре безнең алгы постларыбызга якынайдылар. Вогезы районында немецләрнең аеруча активлыгы сизелде. Аларның алга таба барырга маташулары барсы да уңышсыз чыкты. Диңгездә дә әһәмиятле бер нәрсә дә булмады. Расланмаган хәбәрләргә караганда, Англиянең сугыш кораблары немецләрнең өченче су асты көймәсен батырганнар. Авиациянең активлыгы шактый артты. Безнең самолетларыбызның берсенә дошманның һава һөҗүме оборонасы атака ясаган. Зенит артиллериясенең атуларыннан качып самолет бик нык түбән төшкән һәм бу хәл немецләргә үзләренең белдерүләрендә „Французларның бер самолеты бәреп төшерелде" дип белдерергә мөмкинлек биргән. Самолет исә үз базасына кайтты. Немецләр авиациясенең активлыгы аеруча көчле булды. Германия самолетлары көнчыгыш, төньяк һәм төньяк-көнбатыш Франция өстендә очтылар. Париж өстендә самолетлар 2 тапкыр күренде".

БЕРЛИН, 29 февраль. Германия информация бюросы хәбәр итә: „Көнбатыш фронтта җанлы разведка хәрәкәте булды. Германиянең разведка отрядлары кичә дошманның оборона линиясе янына якын ук килергә тырыштылар. Форбахтан көнчыгыштарак һәм Вейсенборгдан төньяк-көнбатыштарак Германия отрядлары күп кенә кешеләрне плен алдылар. Дошманның 4 кешесе үтерелде һәм ул яраланган кешеләрен сугыш кырында калдырып чигенде. Беттингеннан төньяк-көнбатыштарак һәм Мозельдән көнчыгыштарак бик каты сугыш булды. Бу сугышта Германия разведчикларының көчәйтелгән отряды катнашты".

(ТАСС).

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

29 нчы февральдә Карелия бугазында безнең частьләрнең һөҗүме уңышлы рәвештә киңәюдә дәвам итте. Безнең частьләр Выборг—Валкярви тимер юлын, Нюряпяя, Хейньоки станцияләрен, Пэро станциясен (Выборгдан 9 километр көнчыгыштарак), шулай ук Аласяйнио местечкосын һәм Выборг заливының көнчыгыш ярында Выборгдан 2 километр көньяктарак булган дачаларны алдылар.

28 һәм 29 нчы февральдә безнең частьләр дошманның 28 нче февральдәге сводкада күрсәтелгән ныгытылган 42 оборона пунктыннан тыш 270 ныгытылган оборона пунктын алдылар, шуларның 66 сы тимер-бетоннан ясалган артиллерия корылмалары.

Фронтның башка участкыларында әһәмиятле үзгәрешләр булмады.

Безнең авиация дошманның гаскәрләренә һәм сугыш объектларына актив хәрәкәтләр алып барды. Дошман аэродромнарында һәм һава сугышларында дошманның 36 самолеты юк ителде.

* * *

1 нче мартта Карелия бугазында безнең частьләрнең һөҗүме уңышлы рәвештә киңәюдә дәвам итте. Безнең частьләр Вуокси елгасындагы Пааккола—Коски шарлавыгы районын, Хейньоки шәһәрен, Манниккала местечкосын, Выборг—Сердоболь тимер юлындагы Тали станциясен, Выборг шәһәренең көньяк бистәсен һәм Выборг заливының көнбатыш ярындагы Кейхясниеми мысын алдылар.

Дошман Выборг шәһәрен яндыра.

11 нче февральдән 1 нче мартка кадәр безнең частьләр дошманның ныгытылган 922 оборона пунктын алдылар, шулардан 235 е тимер-бетоннан ясалган артиллерия корылмалары. Дошманның 506 орудиесе, 2.732 пулеметы, 19 танкы, 20 мең снаряды, 10 мең винтовкасы һәм 14 миллионнан артык патроны кулга төшерелде.

Фронтның башка участкыларында әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация дошманның гаскәрләренә һәм сугыш объектларына актив хәрәкәтләр алып барды. Һавада булган сугышларда дошманның 11 самолеты бәреп төшерелде.

11 нче февральдән 1 нче мартка кадәр булган вакыт эчендә дошманның барлыгы 191 самолеты бәреп төшерелде. Шул ук чор эчендә безнең авиация барлыгы 21 самолетын югалтты.

Фин ак гвардеецларына каршы көрәшләрдә катнашучы—Советлар Союзы Герое кече командир, укчы-радист Федор Иванович Лопатин.

Баландин фотосы (ТАСС фото-клишесе).

Бурят-Монголия АССР Верховный Советы Президиумына
Бурят-Монголия АССР Совнаркомына
ВКП(б) ның Бурят-Монголия Өлкә Комитетына

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы һәм Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясе Үзәк Комитеты Бурят-Монголияне ак гвардеецлар һәм интервентлар бандаларыннан азат итүнең XX еллыгы уңае белән Бурят-Монголия Автономияле Совет Социалистик Республикасының эшчеләрен, колхозчыларын һәм интеллигенциясен котлыйлар.

Элек алпавытлар, капиталистлар, купецлар, нойоннар, ламалар һәм шаманнар тарафыннан изелгән һәм рәхимсез эксплоатацияләнгән, царизм тарафыннан ачлыкка һәм үлеп бетүгә дучар ителгән бурят-монгол халкы үткән 20 ел эчендә большевистик партия җитәкчелегендә азат социалистик республика төзеде. Патшаның ярым кыргый һәм артта калган колониясеннән, күчмә хуҗалык иленнән Бурят-Монголия Совет власте елларында чәчәк атучы индустриаль-аграр республика булып, Советлар Союзының аерылгысыз өлеше булып әверелде.

Совет властеның Ленинчел—Сталинчыл милли политикасы аркасында, барлык совет республикаларының һәм беренче чиратта РСФСР ның якыннан торып булышлык итүләре нәтиҗәсендә Бурят-Монголия социалистик төзелешнең барлык өлкәләрендә зур уңышларга иреште.

Бурят-Монголиядә авыр һәм җиңел промышленностьның яңа предприятиеләре төзелде һәм төзелә. Артта калган һәм күпчелеге күчмә булган хуҗалыктан республиканың авыл хуҗалыгы, колхоз строеның җиңүе нәтиҗәсендә, алдынгы социалистик хуҗалык булып әверелде.

Бу уңышлар хезмәт ияләренең материаль һәм культура хәленең тиз үсүен, милли совет интеллигенциясе кадрлары барлыкка килүне тәэмин иттеләр.

Бурят-Монголиянең хезмәт ияләре бу уңышларга социалистик Ватаныбызның дошманнарын—империализмның буржуаз милләтче һәм троцкийчы-бухаринчы агентларын,—ирекле бурят-монгол халкына капиталистик һәм милли изү богавы киертергә маташкан дошманнарны тар-мар итеп, большевиклар партиясе җитәкчелегендә ирештеләр.

ССР Союзы Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты бурят-монгол халкының Советлар Союзының барлык халыклары белән туганнарча дуслыкта булып Бурят-Монголия Автономияле Совет Социалистик Республикасының һәм бөтен Советлар Союзының куәтен киләчәктә дә армый-талмый ныгытачагына ныклы ышаныч белдерәләр.

ССР СОЮЗЫ ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫ. **ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ.**

ФРАНЦИЯДӘ СУГЫШ ВАКТЫНДАГЫ ГАДӘТТӘН ТЫШ ДЕКРЕТЛАР

ПАРИЖ, 29 февраль. (ТАСС). Франциянең министрләр советы бүген сугыш вактындагы күп кенә гадәттән тыш декретларны раслады. Бу декретларның иң беренче максаты—халыкның кулланыуын тагын да киметү. Продукт карточкалары өләшү теләге белән халыкның гомуми учеты алыначак. Булочныйлар, кондитерскилар һәм рестораннар өчен махсус кагыйдәләр билгеләнә. Франция хөкүмәтенең карары буенча моннан соң гади он ногыт борчагы оны белән кушылачак. Нефть продуктлары (керосин, бензин һәм башкалар) сату кими. Франциядә киң куллану продукты булган эчемлек сату киметелә. Шушы декретлар уңае белән бәяләрнең кискен рәвештә күтәреләчәген белеп, Франция хөкүмәте шул ук вакытта базар бәяләренә контроль кую турында гадәттән тыш декрет чыгарды. Аннары авыл хуҗалыгына кагылышлы гадәттән тыш декретлар чыгарыла. Бу декретларда хөкүмәт, мобилизация нәтиҗәсендә авылда эш көчләренең нык җитмәвенә дә карамастан, яз көне барлык җирләргә һәм хәтта фронт тирәсендәге җирләргә дә чәчүне таләп итә. Шулай ук экспортны арттыру чаралары турында, хатын-кызлар хезмәтен куллануны киңәйтү чаралары турында һәм һәр төрле гражданский учреждениеләрнең артык расходларына каршы көрәш чаралары турында да декретлар чыгарыла. Шул ук вакытта сугыш алып бару өчен Франция хөкүмәтенә кирәк булган средстволарны туплау буенча башка төрле чаралар да кулланыла (экспорт өлкәсендә, пошлиналар, налоглар җыю өлкәсендә һ. б.).

ПАРТИЯНЕҢ КАЗАН ШӘҺӘР КОНФЕРЕНЦИЯСЕНӘ КАРАТА

Партия пропагандасы һәм интеллигенция

Казан шәһәренең Молотов районы—ул, югары уку йортлары, техникумнар һәм башка уку йортлары бик күп урнашкан район. Бер Татарстан өчен генә түгел, бәлки бөтен илебез өчен бик күп төрле белгечләр армиясенең шактый өлеше шушы райондагы уку йортларында хәзерләнә.

Меңнәрчә интеллигентларны Ватан эшенә ахрынача бирелгән кадрлар итеп, аларны марксизм-ленинизм белеме белән коралланган кадрлар итеп тәрбияләүдә партиянең Молотов райкомыннан гаять зур оештыру һәм җитәкчелек эше таләп ителә. Һәм әйтергә кирәк: бу өлкәдә, район комитеты тарафыннан шактый эш башкарылган. Райондагы коммунистлардан 1.323 кеше „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н үзлекләреннән өйрәнәләр. Кичке марксизм-ленинизм университетында, югары һәм урта буын түгәрәкләрендә укучы коммунистлар, комсомолецлар һәм партиясезләр саны да зур гына.

Профессорлардан, фәнни работниклардан һәм педагоглардан бик күп иптәшләр марксизм-ленинизм теориясен өйрәнүдә һәм аны пропагандалауда бик яхшы үрнәкләр күрсәтәләр. Боржецов, Мелешенко, Громов, Степанов, Толстяков, Еналеев, Файт, Перменов һәм башка иптәшләр бу өлкәдә районда зур эш алып баралар. Рождественский, Потапов, Николаев, Капитонов, Зателепин, Новоселов, Куцаков, Тамарченко һәм Байгулов иптәшләр „кыскача курс“ны өйрәнүне тәмамлаганнар. Алар хәзер марксизм-ленинизм теориясен төп чыганаклар буенча өйрәнү өстендә эшлиләр.

Партия пропагандасы эшен тиешенчә кую өчен Молотов районында бөтен мөмкинлекләр бар. Чөнки ул культура көчләре районы. Райкомның пропаганда һәм агитация бүлеге кирәкле кадрлар белән тулысынча тәэмин ителгән. Пропагандистларның, консультантларның көчле отряды аның карамагында. Ләкин бу бүлек һәм аның мөдире иптәш Мексина бу көчләрдән тиешенчә һәм тулысынча файдалана алмаган.

Бу районның парткабинеты инде 9—10 ай эшли. Ул кирәкле китаплар һәм ярдәмче материаллар белән тулысынча тәэмин ителгән. Ләкин партия тарихын өйрәнүчеләргә аның булышлыгы канәгатләнерлек булудан бик ерак. Бер елга якын вакыт эчендә парткабинет тарафыннан уздырылган консультацияләрдә бары 502 кеше, индивидуаль консультацияләрдә 486 кеше булган. Бу саннар парткабинетның район активыннан һәм партия тарихын өйрәнүчеләрдән аерым яшәве турында сөйлиләр.

Бу районның уку йортларындагы күп санлы студентлар марксизм-ленинизм нигезләрен уку программасы буенча үтәләр. Коммунист-студентлар арасында укуда алдынгылык өчен, марксизм-ленинизм теориясен өйрәнүдә үрнәк күрсәтү өчен көрәш юк түгел, әлбәттә. Мәсәлән, Казан Дәүләт университетында беренче семестрда марксизм-ленинизм нигезләре буенча экзаменны коммунист-студентларның 35,3 проценты отлично, 52,9 проценты яхшы билгесенә, ә калганнары барсы да канәгатләнерлек билгесенә тапшырдылар. Химия-Технология институтындагы коммунист-студентлардан 20 кешенең 19 ы партия тарихы буенча экзаменнарда отлично һәм яхшы билгеләре алдылар.

Ләкин район күләмендә алганда бу фән буенча студентларның отлично һәм яхшы билгеләренә гомуми өлгереше 62,2 процентттан артмый. Шул ук вакытта Казан Педагогия институтында марксизм-ленинизм нигезләре буенча зачетка килергә тиешле студентларның 10 проценты, Казан Медицина институтында—6,19 проценты зачетка бөтенләй килмәгәннәр. Бу саннар Молотов районындагы ВУЗларда марксизм-ленинизм нигезләрен укыту эше әле тиешле югарылыкта тормауны күрсәтәләр. Шуның белән бергә алар, яшь кадрларны, совет интеллигенциясен тәрбияләү эшенә ВКП(б) райкомының җитәкчелеге һәм контроле җитәрлек булмауны күрсәтәләр.

Молотов районында партия тарихын өйрәнүдән тәм тапмаучы, партия уставының таләпләрен үтәмәүче коммунист—җитәкчеләр һәм укытучылар да юк түгел. Казан Педагогия институты директоры Садыйков, Трампарк директоры Шерестневский, Микоян исемендәге кондитер фабрикасының цех начальнигы Жуков, Фельдшер-акушерлык мәктәбе директоры Семенов иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнү эшенә әле дә чынлап керешмәгәннәр, алар әле дә „вакыт таба алмыйлар“. Шул ук фельдшер-акушерлык мәктәбенең химия укытучысы, партия члены иптәш Матвеев мәктәптәге партоешма тарафыннан үткәрелгән теоретик беседага бөтенләй килмәгән, ул, марксизм-ленинизмны өйрәнү „... Фәннең барлык тармакларындагы большевиклар өчен мәҗбүри булырга тиеш“лекне әлегә кадәр аңламаган.

Совет интеллигенциясен, яшь белгечләрне ленинчеләр итеп тәрбияләү өлкәсендә партия оешмаларына гаять зур бурычлар йөкләнә. „Ленинче булган кеше фәннең үзе яраткан тармагының гына белгече булып кала алмый,—ул бер үк вакытта үз иленең язмышы белән якыннан кызыксынучы, иҗтимагый үсеш законнары белән таныш, бу законнардан файдалана белүче һәм илгә политик җитәкчелеккә актив катнашырга омтылучы политик булырга—җәмагать эшчесе булырга тиеш“. Иптәш Сталинның бу күрсәтмәсен бер вакытта да онытырга ярамый.

З. Габитов.

Райком бүлекләренә оператив җитәкчелек итәргә

Ленин—Сталин партиясе оештыру мәсьәләләренә һәр вакытта да гаять зур игтибар биреп килде. Оештыру эшләрен яхшы итеп кую партия-масса, пропаганда һәм хуҗалык мәсьәләләрен уңышлы хәл кылуда да чиксез зур роль уйный. ВКП(б) ның XVIII нче съезды карары нигезендә райкомнарда оештыру-инструкторлык бүлекләре төзелү хәзерге вакытта оештыру мәсьәләләренең әһәмияте тагын да нык үскәнлекне күрсәтә.

Без, оештыру-инструкторлык бүлеге работниклары, үзебезнең алга куелган бу почетлы бурычны ничек үтибез соң? Ачык итеп әйтергә кирәк: бу эшнең үтәлеше һич тә канәгатләнерлек түгел әле. Башлангыч партоешмаларның шушы көннәрдә булып үткән отчет-сайлау җыелышлары һәм ВКП(б) ның Киров район конференциясе вактында оештыру-инструкторлык бүлегенә карата тәнкыйтнең аеруча көчле булуы моны бик ачык күрсәтә. Барыннан да элек, бу җитешсезлекләр партиянең түбәнге оешмаларында райком иструкторларының сирәк булуларыннан, булган кимчелекләргә алар тарафыннан тирәнтен анализ ясалмаудан һәм партоешма секретарьларына аларның тиешенчә ярдәм итмәүләреннән гыйбарәт.

Безнең эшебездәге кимчелекләр, шул ук вакытта, партия шәһәр комитетының, аерым алганда, аның оештыру-инструкторлык бүлегенең безгә җитәрлек ярдәм күрсәтмәве нәтиҗәсе булып торалар. Мәсәлән, узган елны тәҗрибәләрне уртаклашу буенча оештыру-инструкторлык бүлеге работникларының гомуми шәһәр киңәшмәсе бары тик бер тапкыр үткәрелде. Билгеле, бу киңәшмә инструкторларга үзләренең бурычларын аңлауда һәм эш тәҗрибәләрен баетуда шактый ярдәм итте. Ләкин безнең көндәлек эшебездә еш кына очрый торган күп төрле һәм кыен мәсьәләләрне дөрес хәл итү өчен мондый киңәшмәләр генә безне канәгатләндерә алмыйлар.

Партия сафларының үсешен регулярлаштыру мәсьәләсен алыйк. Шәһәр Комитетының оештыру-инструкторлык бүлеге работниклары бу мәсьәләдә безнең тарафтан җибәрелгән кимчелекләргә вактында тиешле анализ ясап, тиешле күрсәтмә бирә алмадылар. Алар үзләре дә бу мәсьәләнең никадәр мөһим булуын бары тик шул вакытта гына—ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумына һәм партия активының шәһәр җыелышына материал кирәк булгач кына аңладылар булса кирәк. Әгәр шулай булмаса, алар партия сафларына кабул итү турында Киров райкомыннан алынган протоколларны яхшылап укып, өйрәнеп барган булырлар иде. Бу мәсьәләдә безнең кимчелекләрне вактында ук күрсәтә алган булырлар иде.

Шәһәр Комитетының инструкторлары, башлангыч партоешмаларның эшләрен тикшергәндә, аерым хәлләрдә, райком бүлекләренең рольләрен киметүгә кадәр барып җитәләр. Алар күп вакыт, райком бүлекләре белән киңәшеп эшләмиләр һәм тикшерү нәтиҗәләре белән райком җитәкчеләрен таныштырмыйлар. Шуның аркасында еш кына бер үк мәсьәлә белән райком да, Горком да шөгылләнә. Болай эшләү нәтиҗәсендә, башлангыч партоешмаларга ярдәм итүдән бигрәк, аларны төрле якка тарткалау һәм эшләренә комачаулык итү килеп чыга. Билгеле, киләчәктә мондый кимчелекләрнең кабатлануларына һич тә юл куймаска тиеш.

Райкомның оештыру-инструкторлык бүлеге районда нинди җыелышлар (аларны үткәрү урны, вакты, көн тәртибе) һәм нинди чаралар үткәрелү турында Шәһәр Комитетына һәр вакыт информация биреп тора. Билгеле, моның өчен бик күп вакыт кирәк һәм ул безнең оператив эшебезгә бик зур комачаулык итә. Чөнки райондагы йөзләрчә оешманың нинди чаралар үткәрүе турында материал туплау җиңел эш түгел. Шулай ук бу эш башлангыч партоешма секретарьларын да артык борчу була. Минемчә, мондый информациянең кирәге ул кадәр зур түгел һәм киләчәктә бу турыда чын-чыннан уйларга кирәк.

Партиянең Казан шәһәр конференциясе югарыда күрсәтелгән кимчелекләрне большевистик тәнкыйт уты астына алырга һәм аларны бетерүнең практик юлларын билгеләргә тиеш. Шәһәр Комитетының инструкторлары үзләренең күбрәк вакытларын түбәнге оешмаларга җанлы һәм оператив җитәкчелек эшенә бирергә тиешләр. Шул вакытта безнең эшебездә кимчелекләр азрак булыр һәм без, партия-политик эшнең яңа күтәрелешенә ирешербез.

Шәфигуллин.

ВКП(б) ның Киров райкомының оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире.

Зеленодольски шәһәре коммунистларының конференциясе

(Махсус хәбәрчебездән телефон буенча)

Сталинчыл бишьеллыклар чәчәге булган яңа шәһәр—Зеленодольски шәһәре кызу темп белән үсә. Шәһәр предприятиеләрендә быел хезмәт җитештерүчәнлеге 1939 нчы ел белән чагыштырганда 40—50 процентка арту, шәһәр халкының 14 меңнән 32 меңгә үсүе, соңгы ике ел эчендә партияле һәм партиясез большевиклардан 300 дән артык кешенең җитәкче эшләргә күтәрелүе, шәһәр партоешмасының 80 процентка үсүе әнә шул турыда сөйлиләр. Бу сокландыргыч үсеш партиянең шәһәр оешмасы алдына яңа таләпләр куялар.

ВКП(б) ның шәһәр конференциясе делегатлары Шәһәр Комитеты секретаре иптәш Греховның отчет-докладын әнә шул күзлектән чыгып тикшерделәр.

Отчет-доклады буенча фикер алышуларда 32 кеше чыгып сөйләде. Алар ВКП(б) ның Шәһәр Комитеты эшендәге уңышларны күрсәтү белән бергә, практик эштә булган җидди кимчелекләрне большевистик тәнкыйт уты астына алдылар. Газизов, Плоскуров, Домрочева, Шульгин, Трофимова, Горинов, Суганов, Помчалов һәм башка иптәшләр партиянең эчке эше, шәһәрне төзекләндерү, яшь буынны коммунистик тәрбияләү, сәламәтлек саклау, халык мәгарифе, совет сәүдәсе мәсьәләләренә һәм предприятиеләрнең эшенә тукталып, бу мөһим эш тармакларына Шәһәр Комитетының җитәрлек игтибар бирмәвен әйттеләр.

— Шәһәр Комитеты промышленность предприятиеләре эшенә—ди иптәш Помчалов,—кабинеттан торып кына җитәкчелек итә. Шәһәр Комитетының инструкторлары күп вакыт теге яки бу мәсьәлә буенча төрле маглүматлар җыю белән генә чикләнәләр. Шәһәр Комитеты үз карарларының үтәлешен тикшерми. Тимер юл станциясе һәм шулай ук заводлар турында чыгарылган карарларның бик тиз онытылулары мона ачык мисаль.

Партия оешмаларының һәм аерым коммунистларның сигналларына ВКП(б) ның Шәһәр Комитеты игтибар итмәгән. Моны делегатлар үз речьләрендә конкрет фактлар белән расладылар.

Конференция ВКП(б) Шәһәр Комитетының практик эшен канәгатләнерлек дип тапты һәм эштә булган җидди кимчелекләрне бетерү буенча конкрет чаралар билгеләде.

2 нче мартта мандат комиссиясенең докладыннан соң сайлаулар башланды.

Ким Баков.

Мәктәпләрдәге партоешмаларга конкрет җитәкчелек кирәк

Казан тимер юлының 1 нче номерлы урта мәктәбендә партиянең кандидатлар группасы бар. Мәктәптәге 56 работник арасында партия-масса эшләрен оештыру буенча һәм 887 укучыны коммунистик тәрбияләү эшенә җитәкчелек итү буенча кандидатлар группасына зур җаваплы бурычлар йөкләнә. Бу бурычларны үтәүдә кандидатлар группасына партиянең Сталин райкомы һәм Шәһәр Комитеты тарафыннан конкрет булышлык таләп ителә. Ачык әйтергә кирәк: алар тарафыннан бу ярдәм җитәрлек түгел. Партиянең мәктәпләрдәге оешмаларының эшен махсус вәкилләр аркылы тикшерү белән генә чикләнәләр.

Менә бер факт. Башлангыч партоешмаларда отчет-сайлау җыелышлары башланыр алдыннан Шәһәр Комитеты безнең мәктәптәге кандидатлар группасын тикшерү өчен вәкил итеп Касыймов дигән бер иптәшне җибәргән иде. Ул, кандидатлар группасының кайбер эшләре турында бик өстән генә сорашу белән чикләнде. Коммунистлар һәм партиясез интеллигенция арасында „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнү һәм агитация-масса эшләренең торышы белән, мәктәп коллективының тормышы белән бөтенләй кызыксынмады. Ул җыелыш протоколларын алып бару һәм партдокументларны саклау турында кайбер күрсәтмәләрне әйтү белән генә чикләнде. Аның тикшерү нәтиҗәләре безгә җиткерелмәде. Без аннан партия-масса эшләрен оештыру буенча булган кимчелекләребезне күрсәтүне һәм эшне яхшырту буенча практик чаралар билгеләшүне көткән идек. Ләкин алай булып чыкмады.

Райком җитәкчелегенә карата да шундый фактларны китерергә мөмкин. Райком безнең эшкә турыдан-туры көндәлек булышлык күрсәтергә тиеш. Ләкин менә мин бу мәктәптә 3 ел эшлим инде, райкомның конкрет җитәкчелеге сизелми. Безнең мәктәпкә беркетелгән иптәш Исмагыйлов, хәтта отчет җыелышына да килмәде. Февраль аеның уртасында ничектер бер комиссия генә килеп чыкты. Ул комиссия бездә берничә көн булды, 8 дәрескә керде, педсоветның протоколларын карады. Менә шуннан соң бер атнадан артык вакыт үтте инде, әле комиссиянең нәтиҗәләре ишетелгәне юк. Укытучылар ул турыда сорап аптыратып бетерделәр инде. Чөнки аларның соравы бик урынлы. Тикшерү ясалгач, аның нәтиҗәсе дә җиткерелергә тиеш иде.

Җыеп кына әйткәндә, бу фактлар Шәһәр Комитетының һәм райкомның мәктәпләрдәге партоешмаларның эшенә бик формаль карауларын күрсәтәләр.

Мәктәпләрдәге партоешмаларның эшләренә райкомның һәм Шәһәр Комитетының конкрет җитәкчелек итүләрен булдырырга, яшь буынны тәрбияләүчеләр арасында политик-масса эшләрен бүгенге таләпләргә җавап бирерлек итеп оештырырга кирәк.

Крылова.

Кандидатлар группасы җитәкчесе.

ОТЧЕТ-САЙЛАУ ҖЫЕЛЫШЛАРЫНЫҢ КАЙБЕР ЙОМГАКЛАРЫ

Партиянең Казан шәһәрендәге башлангыч оешмаларында отчет-сайлау җыелышлары гаять зур оешканлык һәм күтәренкелек белән үттеләр. Коммунистлар Ленин—Сталин партиясенең тарихи XVIII нче съезды карарларын тормышка ашыруда партоешмаларның ирешкән уңышларын күрсәтү белән бергә, практик эштә бу көнгә кадәр яшәп килгән җидди кимчелекләрне каты тәнкыйт уты астына алдылар. Алар тәнкыйтләп кенә калмадылар, ә бәлки башлангыч оешмаларның эшләрен яхшырту буенча конкрет чаралар да билгеләделәр.

Казан шәһәрендә партиянең 412 башлангыч оешмасында отчет-сайлау җыелышлары үткәрелде. Бу җыелышларга ВКП(б) членнарыннан 6.301 кеше, кандидатлардан 2.888 кеше катнашты.

Оешма секретарьларының отчет докладлары буенча фикер алышуларда коммунистлар актив катнаштылар. Җыелышларда 3.930 кеше, ягни җыелышларга катнашучы барлык коммунистларның 42,8 проценты чыгып сөйләде. Партиянең күпчелек оешмалары отчет чорында үз алларына куелган бурычларны үтәү өчен көрәшне большевикларча оештыра алсалар да, ләкин, кайбер оешмаларның җитәкчеләре моны эшләгәннәр дип әйтеп булмый. Байтак оешмаларның җитәкчеләре ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын тормышка ашыру өчен йомшак көрәшкәннәр, партия-масса эшләрен хуҗалык эшләре белән бәйләп алып бармаганнар, кадрларны сайлап алуга һәм идея-политик яктан тәрбияләүгә тиешле игтибар бирмәгәннәр. Билгеле, җыелышларда чыгып сөйләүче иптәшләр бу кимчелекләрне ачып салдылар һәм кискен рәвештә тәнкыйтләп, аларны тиз арада бетерү өчен конкрет тәкдимнәр керттеләр.

Партиянең Казан шәһәрендәге башлангыч оешмалары үз алларына куелган политик-хуҗалык бурычларны гомумән начар үтәмәгәннәр. Отчет-сайлау җыелышлары булып үткән 412 оешмадан 294 оешмада (71,8 процент) башлангыч оешманың практик эше канәгатләнерлек дип табылуы моны ачык раслый. Бу, партия кадрларының үз бурычларын үтәү өчен большевикларча көрәшүләрен, партия һәм хөкүмәт карарларын тормышка ашыруда коммунистларның сәләтле булуларын тагын да ачыграк күрсәтә.

Партия органнарына лаеклы иптәшләрне, Ленин—Сталин эшенә нын күңелдән бирелгән, үзен практик эштә күрсәтә алган, политик тотнаклы иптәшләрне сайлау мәсьәләсенә коммунистлар аеруча әһәмият бирделәр. Бу түбәндәге саннарда бик ачык күренә. Бюро составының элекке членнарыннан 378 кеше (56,8 процент) бюроның яңа составына сайланмады. 213 кеше (32 процент) бюро членнары итеп беренче тапкыр сайланды. Партия органнарына сайланучылар арасында социаль чыгыш ягыннан: эшчеләр—285 кеше (42,8 процент), крестьяннар—69 кеше (10,4 процент), хезмәткәрләр һәм башкалар 312 кеше (46,8 процент).

Партия органнарына сайланучыларның белем дәрәҗәләре дә үткән сайлауларга караганда шактый өстен. Партиянең җитәкче органнарына сайланучылар арасында югары белемле—150 һәм урта белемле 191 кеше бар. Партия стажы ягыннан караганда үзгәреш шактый зур. Партиягә 1917 нче елга кадәр керүчеләр—4 кеше, 1918—1930 нчы елларда керүчеләр—392 һәм аннан соңгы елларда керүчеләр 270 кеше.

Сайлауларга кадәр партоешмаларда секретарь булып эшләүчеләр—244 кеше (59,2 процент), башлангыч оешмаларга беренче тапкыр секретарь итеп сайланучылар—167 кеше (40,5 процент). Шул исәптән: хатын-кызлар—69 кеше (16,7 процент).

Социаль чыгыш ягыннан: эшчеләр—219 кеше (53,2 процент), крестьяннәр—59 кеше (14,3 процент), хезмәткәрләр һәм башкалар—134 кеше (32,5 процент).

Белем ягыннан югары белемлеләр—60 кеше (14,6 процент), урта белемлеләр—119 кеше (28,9 процент), түбән белемлеләр—233 кеше (56,5 процент), төгәлләнгән югары политик белемлеләр—40 кеше (9,7 процент) һәм төгәлләнгән урта политик белемлеләр—63 кеше (15,3 процент).

Партстаж ягыннан: 1917 нче елга кадәр партиягә член булып керүчеләрдән—1 кеше (0,2 процент), партиядә 1918—1920 нче еллардан бирле член булып торучылардан—30 кеше (7,3 процент), 1921—1923 нче еллардан бирле торучылардан—6 кеше (1,5 процент), 1924 нче елдан бирле торучылардан—13 (3,1 процент), 1925—1927 нче еллардан бирле торучылардан—98 кеше (33,8 процент), 1928—1930 нчы еллардан бирле торучылардан—88 кеше (21,4 процент), 1931—1936 нчы еллардан бирле торучылардан—119 кеше (28,9 процент) һәм партиягә 1937 нче елда һәм аннан соң керүчеләрдән 57 кеше (13,8 процент).

Бу саннардан Казан шәһәрендәге башлангыч партоешмаларының туктаусыз үсүен ачык күрергә мөмкин. Ләкин шуның белән, бу саннар турыдан-туры производствода эшләүче эшчеләр санының секретарьлар составында кимүен күрсәтәләр. Элекке составта алар 16 кеше иде, бу сайлауларда бары тик 9 кеше. Бу факт эшчеләр арасыннан партия кадрлары сайлап алуга, аларны тәрбияләп үстерүгә һәм күтәрүгә җитәрлек игтибар бирмәвне күрсәтә. Партиянең башлангыч оешмалары үзләренең практик эшләрендә бу мөһим политик мәсьәләгә аеруча игтибар бирергә тиешләр.

Партиянең башлангыч оешмаларында отчет-сайлау җыелышлары тәмам булды. Хәзер бурыч партия оешмаларының эшен тагын да ныгытуга ирешүдән, партия кадрларын большевистик чыныктырудан, аларның идея-политик яктан үсүләренә конкрет булышлык күрсәтүдән гыйбарәт.

ПАРТИЯНЕҢ ШӘҺӘР РАЙКОМНАРЫНЫҢ ПЛЕНУМНАРЫ

СТАЛИН РАЙОНЫНДА

ВКП(б) ның Сталин район конференциясе 29 нчы февральдә үзенең эшен тәмамлады. Ябык (яшрен) тавышка кую тәртибендә райком пленумы составына 45 член һәм 11 кандидат, партиянең шәһәр конференциясенә тавыш бирү хокукы белән 80 һәм киңәш бирү хокукы белән 21 делегат сайланды.

1 нче мартта райком пленумы булды. Пленум райкомның беренче секретаре итеп иптәш Гаязетдиновны, икенче секретаре итеп иптәш Тыйшкевичны һәм өченче секретаре итеп иптәш Шаиховны сайлады.

Аннары пленум райкомның бүлек мөдирләрен раслау эшен карады. Кадрлар бүлегенең мөдире итеп Кротова, пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире итеп Низамов, оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире итеп Парфенов, хәрби бүлек мөдире итеп Жаринов иптәшләр расланды. *А.*

МОЛОТОВ РАЙОНЫНДА

Кичә Молотов райкомының беренче пленумы булып үтте. Пленум райкомның беренче секретаре итеп С. Е. Прокофьев, икенче секретаре итеп Г. С. Сафин һәм өченче секретаре итеп Г. С. Маркухин иптәшләрне бер тавыштан сайлады. Бюро составына С. Е. Прокофьев, Г. С. Сафин, Г. С. Маркухин, Зинанов, Мексина, Мишнев һәм Ситников иптәшләр сайландылар. Пленум райкомның пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире итеп Мексина, оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире итеп Козлов иптәшләрне раслады. *Б.*

БАУМАН РАЙОНЫНДА

1 нче мартта Бауман райкомының пленумы булды. Пленум, райкомның беренче секретаре итеп иптәш Мельниковны, икенче секретаре итеп иптәш Фахрутдинованы, өченче секретаре итеп иптәш Семеновны сайлады. Райком бюросы составына Феоктистов, Матвеев, Мильников, Фахрутдинова, Семенов, Габдрашитов һәм Шәһиахметов иптәшләр сайландылар.

Пленум, райкомның пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире итеп иптәш Габдрашитовны, аның урынбасары итеп иптәш Савельеваны, оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире итеп иптәш Антоновны, хәрби бүлек мөдире итеп иптәш Шәһиахметовны раслады. *Ш.*

КИРОВ РАЙОНЫНДА

29 нчы февральдә Киров райкомының беренче пленумы булды. Пленум ВКП(б) райкомының бюро составын 7 член, 2 кандидаттан сайлады. Райкомның беренче секретаре итеп Тихонов, икенче секретаре итеп Закиров, кадрлар буенча секретарь итеп Казаков иптәшләр сайландылар. Шулай ук пленум райкомның бүлек мөдирләрен раслады. Оештыру-инструкторлык бүлеге мөдире итеп Шәфигуллин, агитация-пропаганда бүлеге мөдире итеп Шепетова, кадрлар бүлеге мөдире итеп Елиссева иптәшләр расландылар. Хәрби бүлек мөдирен раслау эше бюрога тапшырылды.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕК

Орлык белән үзара ярдәмләшү

Орлык туплау—язгы чәчүгә хәзерлектә иң җаваплы эш. Күптән түгел генә әле Теләче районында бу мәсьәләдә хәл яхшы түгел иде. Чәчү орлыклары җитәрлек булмаган кайбер колхоз җитәкчеләре хәтта дәүләттән орлык ссудасы алу турында уйлый башлаганнар иде.

ВКП(б) Өлкә Комитетының VIII нче пленумыннан соң без, җитми торган орлыкны районның үзендә табу чарасына керештек һәм, чыннан да, дәүләттән бер нинди ссуда алмыйча да районны орлык белән тулысынча тәэмин итәргә мөмкин диган нәтиҗәгә килдек.

Барыннан да элек, районның барлык колхозларында да ашлык-фураж балансларын тикшереп чыктык. Тикшерү нәтиҗәсендә, 13 колхозда барлыгы 3.813 центнер орлык җитмәгәнлеге билгеле булды. Ә шул ук вакытта күп кенә колхозларда орлык артык булып чыкты.

Ашлык-фураж балансларын тикшерүдә һәм гомумән шул эшне оештыруда безгә колхоз җитәкчеләре һәм колхозчылар үзләре якыннан торып булышлык иттеләр. Алар колхозлар арасында орлык һәм фураж белән бер-берсенә булышуны үзләре башлап җибәрделәр. Бу эштә „Кызыл Янбулат“ колхозы председателе иптәш Гәрәевнең зур инициатива күрсәтүен әйтергә кирәк. Аның киңәше буенча бу колхоз членнарының гомуми җыелышы үткән елны игеннәренең шактый өлешен боз суккан күрше „Төрекбаш“ колхозына колхоз фондыннан бурычка 600 центнер орлык бирергә карар чыгарды.

„Кызыл Янбулат“ колхозыннан башка колхозлар да үрнәк алдылар. Чәчү орлыклары җитми торган колхозларга бирү өчен „Кремль“ колхозы 530 центнер, „Чулпан“ колхозы—487 центнер, „Марс № 1“ колхозы—326 центнер, Вахитов исемендәге колхоз—300 центнер орлык билгеләп куйдылар. Шулай итеп, без район эченнән 4.500 центнер орлык таптык. Һәм хәзер инде безнең районыбызның колхозлары барлык культуралар буенча орлык белән тәэмин ителделәр.

Районның кайбер колхозларында дөрес планлаштырмау һәм бигрәк тә саксыз тоту нәтиҗәсендә, фураж җитмәү куркынычы бар. Алдынгы колхозларыбыз бу мәсьәләдә дә үзара булышлык оештыралар. Мәсәлән, „Таш Кичү“ колхозы үзенең фураж запасыннан Тукай исемендәге колхозга бирү өчен 200 центнер билгеләп куйды.

Фураж фондларын җентекләп тикшерүне һәм фураждан нык экономия белән файдалануны оештырып, без шулай ук фураж мәсьәләсендә дә кыенлыкны җиңеп чыгачагыбызга нык ышанабыз.

С. Искәндәрев.



„Авангард“ колхозының (Юдино районы) беренче бригада бригадиры иптәш А. В. Антонов (унда) ремонтланган сабаннарны колхоз тимерчесе иптәш В. Н. Петровтан кабул итә.
И. Галиев фотосы.

БЕЗНЕҢ КАЙБЕР ТӘҖРИБӘЛӘР

Без үзебезнең колхозда тәҗрибә эшләре алып баруны 1935 нче елны башладык. Шул елны тәҗрибә өчен 5 гектар мәйданга арпа чәчкән идек. Ул елгы тәҗрибә яхшы нәтиҗәләр бирде, бездә зур кызыксыну тудырды. 1936 нчы елны инде бәрәңге утырту эшендә дә тәҗрибә үткәрдек. Тәҗрибә өчен 4 гектар бәрәңге утырттык. Бу участкыны бәрәңге утыртканчы бик нык эшкәрттек, тиресләдек, тик яровойлаштырылган орлыклар гына кулландык. Өч тапкыр төбенә өйдек. Без бу мәйданның һәр гектарыннан 2.932 пот бәрәңге уңышы алдык. Шушы кечкенә генә участкыда үткәргән чаралар җир эшләүдәге тәҗрибәбезне баетты. Агрономия фәненә өйрәнүгә зур кызыксыну туды. Хәзер безнең колхоз тәҗрибә эшләрен даими алып бара.

1937 нче елны тәҗрибә участкысын арттырдык: 10 гектар арыш, 10 гектар бодай чәчтек. Арыш участкысын язга чыгу белән бер кат тырмаладык. Аннан соң 7 центнер фекальгә 12 тонна су кушып ясалган сыекча белән тукландыру үткәрдек. Тукландырганнан соң бераз вакыт үткәч тагын тырмаладык. Бу чаралар начар нәтиҗә бирмәде: һәр гектардан 196 пот уңыш алдык.

Бодай өчен билгеләнгән участкыны көз көне яхшы итеп тунга сөреп калдырдык. Яз көне һәр гектарга 10 тонна исәбеннән тирес керттек. Аннары 17 сантиметр тирәнлектә тагын сөрдек. Диагональ тәртибендә культивация үткәрдек. Орлык яровойлаштырып чәчелде. Шуларның барсы нәтиҗәсендә әлеге участкының һәр гектарыннан 158 пот бодай уңышы алуга ирештек.

1938 нче елны төрле культуралар буенча тәҗрибә үткәрдек. Аерым алганда, өч төрле сорт кара бодайны бишәр килограмм күләмендә чәчтек. „Богатырь“ сортының 5 килограммы—63 килограмм уңыш бирде, „Авангард“ сортының 5 килограммы—1 центнер 17 килограмм, „Бурят-Монгол“ сорты—90 килограмм уңыш бирде.

1939 нчы елда да шундый ук чаралар үткәрү белән чәчелгән 10 гектар арпаның һәр гектары 14,3 центнер уңыш бирде. Солының „Московский А—315“ һәм „Победа“ сортлары буенча үткәрелгән тәҗрибәләр дә уңышлы нәтиҗә бирделәр.

Хәзер без 1940 нчы ел язына хәзерләнәбез. Мин 1940 нчы елны югары уңыш өчен Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә алган тәҗрибәләремне практикага ашырам. Безнең колхозда һәрбер бригада, һәрбер звено һәм һәрбер колхозчы үзара ярышып эшли.

Беренче нәтиҗәләр күз алдында: колхоз басуга тирес чыгару планын 114 процент үтәде. 420 гектар мәйданда кар тоту үткәрелде. Кош тизәге җыю планы 70 процент үтәлде. 96 центнер фекаль җыйдык. Чәчү орлыклары яхшы сыйфатлы итеп чистартылды. Барлык бригадаларда да агрономия укулары оештырдык. Анда бригада саен 20—25 колхозчы укый. Бригадирлар һәм звено башлыклары өчен агрономия фәнен өйрәнү буенча югарырак типтагы түгәрәк эшли.

Гыймазетдинов.
Алабуга районының „Яш көч“ колхозы агротехнигы.

ТЫМЫТЫК МТС КОЛЛЕКТИВЫ ЙӨКЛӘМӘСЕ

ТЫМЫТЫК. (Телеграф буенча). Тымытык МТС алдынгыларыннан бригадир Кәримев һәм комбайнчы Дәүләтшин иптәшләрнең алтын медальләр белән бүләкләнүләре уңае белән МТС работникларының митингысы булды.

МТС коллективы быел һәрбер трактор белән кимендә 1.000 гектар эшләргә, һәрбер комбайн белән 500 гектар урып-җыярга һәм МТС хезмәт күрсәтә торган колхозларда бөртекле культураларның һәр гектарыннан йөз пот иген уңышы алырга йөкләмә кабул итте.

Алтын медальле иптәш Кәримев быел үз бригадасында һәрбер ЧТЗ тракторы белән 3.500 гектар эшләргә, комбайнчы иптәш Кәлимуллин 800 гектар урып-җыюга йөкләмә алдылар.

Галәветдинов.
МТС директоры.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕКНЕ ҮЗАРА ТИКШЕРҮ

Юдино районы колхозларында язгы чәчүгә хәзерлекне үзара тикшерү киң күләмдә җәелде. Тикшерү нәтиҗәсендә аерым колхозларның язны тулы хәзерлек белән каршылаулары беленде.

Киров исемендәге колхозда чәчүлек орлык иң югары кондициягә җиткерелгән һәм коры амбарларда саклана. Шул колхозның иптәш Сабиров бригадасы язгы чәчүгә аеруча яхшы хәзерләнгән. Барлык машиналарга, сбруйларга һәм транспортка ремонт отлично сыйфатлы итеп ясалган. Бригада членнары агротехника түгәрәкләрендә укыйлар. Звено башлыклары өчен аерым занятиеләр үткәреләр. Аларны колхоз агротехнигы иптәш Шәрәфиев укыта. Бу колхоздан 5 кыз тракторчылар курсында укый.

Фрунзе исемендәге колхоз да язгы чәчүгә хәзер. Колхозчылар стахановчылар мәктәбендә укыйлар. Колхозда 100 тоннадан артык җирле ашламалар хәзерләнгән. Орлык яхшы тазартылган һәм тишелүчәнлеге тикшерелгән. Атларның көрлеге яхшы.

„Пионер“, „Марс № 1“ һәм Буденный исемендәге колхозлар да язгы чәчүгә тулысынча хәзерләнгәннәр.

(ТатТАСС).

ҖИРЛЕ ПРОМЫШЛЕННОСТЬ КАДРЛАРЫ

Татарстанның җирле промышленность наркоматы кадрлар хәзерләү өчен һәр елны бик зур сумалар тота. 1939 нчы елда гына да бу эшкә 400 мең сумга якын акча тотылган. Быел бу эшкә 600 мең сум билгеләнде.

Предприятиеләрдә кадрлар хәзерләү эше—эшчеләрне техника укуларына тарту, аларны социалистик хезмәт мастерлары курсларында һәм тематик курсларда укыту, шулай ук производство инструктажлары үткәрү юлы белән алып барыла.

Наркомат 1939 нчы елда кадрлар хәзерләү планын 114 процент итеп үтәгән. Узган ел предприятиеләрдә оештырылган техминимум түгәрәкләрендә, социалистик хезмәт мастерлары курсларында, шулай ук башка төрле кыска сроклы курсларда барлыгы 1.695 кеше укып чыкты һәм дәүләт техника сынавын тапшырды. Шуның өстенә җирле промышленность предприятиеләрендә эшләүче җитәкче работниклар өчен оештырылган югары типтагы техника укуы түгәрәкләрендә 23 кеше, производстводан аерылып, урта квалификация алу курсларында 41 кеше, транспорт һәм энергетика кадрлары хәзерләү курсларында 19 кеше укып чыкты һ. б.

Теоретик хәзерлекләре җитәрлек булмаган практик инженер-техник работниклардан, цех начальникларыннан, мастерлардан һәм иң яхшы стахановчылардан 68 кеше узган ел җирле промышленность наркоматы институтын читтән торып уку тәртибендә тәмамлады. 21 кеше институтта укуларын дәвам иттерәләр. Инженер-техник работниклардан 8 кеше читтән торып Промакадемиядә укый.

Наркомат карамагында булган „Красный Путь“ заводы һәм Татполиграф каршында ФЗУ мәктәпләре эшләп килә. Бу мәктәпләрдә укучылар слесарьлык, токарьлык, тимерчелек эшләренә, хәреф коярга һәм башка күп кенә квалификацияләргә өйрәнәләр. Узган ел бу мәктәпләрдә 184 кеше укып чыкты. ФЗУ мәктәпләреннән производствога килгән иптәшләр хәзер алдынгы стахановчылар булып бастылар һәм хезмәт җитештерүчәнлегенең югары күрсәткечләрен бирәләр. Алар арасында мастер, хәтта цех начальнигы постына кадәр күтәрелгән иптәшләр бар.

Техника укуы—производство планын үтәү өчен көрәшнең аерылмас бер өлеше. Үз эшләренең техникасын нык үзләштергән, техника сынавын отлично һәм яхшы билгеләренә тапшырган эшчеләр хезмәт җитештерүчәнлегенең сокланырлык үрнәкләрен күрсәтәләр.

Менә бернечә факт. Иптәш Жоголев „Красный Путь“ заводына гади эшче булып керде. Техминимум түгәрәгенә йөргәнгә кадәр ул көнлек норманы 130 процент итеп үти иде. Түгәрәктә укып, техминимум буенча дәүләт техника сынавын отличнога тапшырганнан соң, иптәш Жоголев көнлек норманы 480 процентка кадәр үти башлады. Хәзер ул стахановчылар мәктәбендә укый.

Шул ук заводта элек көнлек норманы чак-чак кына үтәп килгән Тимофеев һәм Кузнецов иптәшләр техминимум буенча сынауларны уңышлы тапшырганнан соң, норманы 2—3 тапкырдан да арттырып үти башладылар.

Гармон фабрикасына гади эшче булып кергән иптәш Пермяков хәзер мастер итеп күтәрелде. 1939 нчы елда иптәш Пермяков инженер-техник работниклары курсын тәмамлады. Хәзер ул механика цехы начальнигы булып эшли. Шушы ук фабрикада эшләүче иптәш Карпухин үзенең техник белемен күтәрү өстендә бер туктаусыз эшли. Ул башта бригадирлык постына, аннан соң техник контроль бүлегенә күтәрелде. Хәзер иптәш Карпухин музыка коралларына ремонт ясау цехы начальнигы булып эшли. Техника сынавын отличнога тапшырган Зиннурова һәм Евлантьева иптәшләр бригадир итеп күтәрелделәр. Элекке гади эшче, хәзер производство командирлары булу дәрәҗәсенә күтәрелгән кадрларны җирле промышленность предприятиеләрендә күпләп санарга мөмкин.

Производство инструктажы техника укуларының бер төре. Үзләренең нормаларын үти алмаучы эшчеләр өчен производство инструктажлары үткәрүнең әһәмияте гаят зур. Ләкин җирле промышленность предприятиеләрендә бу эшнең куелышы канәгатьләнерлек түгел әле. Бу эш өчен җибәрелгән средстволар күбесенчә урынсызга әрәм-шәрәм ителәләр. Инструкторлар программалар белән тәэмин ителмиләр, аларның эшен берәү дә тикшерми. Производство инструктажларын үткәрүгә бәя биреп җиткермәүчелек бетерелергә тиеш. Тәҗрибәләрне уртаклашу эшен яхшы итеп оештыру стахановчылык хәрәкәтенең тагын да үсүенә көчле этәргеч булуын онытмаска кирәк.

Түгәрәкләрдә, социалистик хезмәт мастерлары курсларында, институтның читтән торып уку филиалында һәм башка төрле курсларда укытучыларның белем дәрәҗәләре җитәрлек булмавын аеруча әйтергә кирәк. 79 укытучының бары 23 генә югары белемле. 31 кеше урта һәм түбән белемле практиклар.

Татар группалары специаль һәм башка төрле фәннәр буенча татар телендәге дәреслекләр белән тәэмин ителмәгәннәр. Менә бу кимчелекләр якын арада бетерелгәндә, кадрлар хәзерләү эше тагын да яхшырачак, әлбәттә.

Ф. Сагдеева.

ИПТӘШ СТАЛИННЫҢ „УҢЫШЛАРДАН БАШ ӘЙЛӘНҮ“ ИСЕМЛЕ МӘКАЛӘСЕНЕҢ 10 ЕЛЛЫГЫНА КАРАТА

Илебезнең авыл хуҗалыгы үсешендә 1929 нчы елда инде тамырыннан борылыш ясалды. Эшчеләр белән крестьяннәрнең союзын ныгыту буенча партиянең Ленинчел—Сталинчыл политикасы, илне социалистик индустрияләштерү политикасының җиңүе, кулакларга каршы кискен көрәш, беренче колхозларның һәм совхозларның уңышлары, колхоз строеның өстенлеге турында авылда партия һәм Совет хөкүмәте тарафыннан үткәрелгән зур аңлату эше—болар барсы да 1929 нчы елга илебезнең крестьяннәрен колхозлар юлына таба тарихи борылышка хәзерләде. Бу ел илебездә социализмның җиңүе өчен көрәш тарихына социалистик төзелешнең барлык фронтларында бөек борылыш елы булып керде.

Киң катлау крестьяннәр массасының коллективлашу юлына борылуы партиягә һәм Совет властена кулакларны чикләү һәм кысрыклау политикасыннан тоташтан коллективлаштыру нигезендә кулакларны сыйныф булу ягыннан бетерү политикасына күчү бурычын куярга мөмкинлек бирде. Бу вакытта инде илебездә кулакларга каршы җиңүчән һөҗүм үткәрү өчен материаль база төзелгән иде: 1929 нчы елны ук инде колхозлар һәм совхозлар илебезгә 130 миллион поттан артык товарлыклы ашлык бирделәр. Бу 1927 нче елны кулаклар җитештергән ашлыктан шактый артык иде. Илдә социалистик индустрияләштерү планын үтәү дә уңышлы барды һәм ул авыл хуҗалыгын техника белән яңадан кораллandыру өчен база тудырды.

1930 нчы елның 5 нче январенда „Коллективлаштыру темпы һәм колхоз төзелешенә дәүләтнең ярдәм чаралары турында“ ВКП(б) Үзәк Комитетының тарихи карары иглан ителде. Бу карарда миллионнарча вак һәм таркау ялгыз хуҗалыкларны коллектив социалистик хуҗалык юлына күчерүнең сроклары һәм методлары турында Сталинча ачык һәм дөрес күрсәтмәләр бирелде. ВКП(б) Үзәк Комитеты СССР районнарының шартлары төрле булуны һәм коллективлашуга аларның хәзерлек дәрәҗәләрен исәпкә алып, коллективлашуда төрле темплар билгеләде. Шул ук карарда авыл хуҗалыгы артеленең хәзерге этапта колхоз хәрәкәтенең төп формасы булуы турында һәм артельдә төп җитештерү средстволарының гына җәмагатьләштереләчәге турында гаят әһәмиятле күрсәтмә бирелде. ВКП(б) Үзәк Комитеты колхоз хәрәкәтен нинди төстә булса да „декретлаштыру“ га каршы партия оешмаларын кисәтте.

Шуның белән бергә Үзәк Комитет тракторлар, комбайннар һәм башка авыл хуҗалыгы машиналары эшләүче заводларны арттыру һәм аларны төзүне тизләтү кирәклекне күрсәтте.

Колхоз төзелешендә Ленин—Сталин юлы нигезендә бөтен илдә большевиклар партиясе җитәкчелегендә куәтле колхоз хәрәкәте җәелдерелде. Кулакларның котырынган каршылыкларын җиңеп, кулакларның агентурасы булган троцкичы-зиновьевчы капитулянтлар блогын һәм уң капитулянтларны фаш итеп, партия хезмәт иясе крестьяннәрне коллективлаштыру юлы белән алып барды. Крестьяннәр колхозларга кереп, иске авыл строен яңа социалистик строй белән алмаштырдылар.

Ләкин гаят зур уңышлар белән бер рәттән, урыннарда колхоз төзелешендә зур кимчелекләр һәм партия политикасын бозулар барлыгы да беленде. ВКП(б) Үзәк Комитетының ачык һәм дөрес күрсәтмәләре булуга да карамастан, партия һәм совет җитәкчеләренең бер өлеше, коллективлаштыру уңышлары белән мавыгып, коллективлаштыру темпларын ясалма төстә кызулата башлады, ышандыру методларын крестьян хуҗалыкларын коллективлаштыруны бюрократларча декретлаштыру белән алмаштыра башлады. Артельне колхоз хәрәкәтенең төп формасы итәсе урында, „сул“ бөгелешчеләр кинәт коммуналар оештыра башладылар, җитештерү коралларын һәм эш терлекләрен генә түгел, хәтта торак йортларын, вак терлекләрне, йорт кошларын һәм башкаларны да көчләп җәмагатьләштерә башладылар.

Иптәш Сталин күрсәткәнчә, бу—партиябезнең тормышында иң куркынычлы чорларның берсе иде.

„Уңышлар белән мавыгып, зур тизлек белән түбәнгә тәгәрәгән, партия линиясеннән читкә тәгәрәгән кадрларның—партия кадрларының шактый өлешен үз вактында туры юлга борып җибәрү өчен Үзәк Комитетның гаят зур ныклыгы, аның **агымга каршы** бара белүе кирәк булды“. („ВКП(б) тарихы“, бит 349—350).

1930 нчы елның 2 нче мартында ВКП(б) Үзәк Комитеты карары буенча иптәш Сталинның „Уңышлардан баш әйләнү“ исемле тарихи мәкаләсе басылып чыкты. Колхоз төзелешендә бу мәкаләнең әһәмияте гаят зур булды.

Иптәш Сталин, авылда колхоз политикасының уңышларын күрсәтеп, бу уңышларның еш кына кешеләрне исертүен, аларның башлары әйләнә башлаганлыкны, чамалау хисе югалганлыкны, үзләренең көчләренә артык бәя бирергә, дошманның көчләренә бәя биреп җиткермәскә омтылыш туа башлаганлыкны, социалистик төзелешнең барлык мәсьәләләрен „бер селтәнү белән“ хәл итәргә авантюристларча маташулар барлыкны әйтте. Иптәш Сталин эш өчен бу куркынычлы һәм зарарлы настроениеләргә каршы кискен көрәш алып бару бурычын куйды. Колхоз хәрәкәтен һәлак итү куркынычын тудырган „сул“ бөгелешләргә каршы иптәш Сталин бөтен көче белән ташланды. Колхоз төзелешенең иреклелек принципын нык күрсәтеп, иптәш Сталин, коллективлаштыру темпларын һәм методларын билгеләгәндә СССР ның төрле районнарындагы шартларның үзгәлеген исәпкә алырга кирәклекне әйтте.

Иптәш Сталин колхозларны көчләп оештырырга ярамый диде, колхоз хәрәкәтен декретлаштырырга ярамый, чөнки бу бозуларның дошманнарның көчәюенә һәм колхоз хәрәкәте идеяләренең таралуына китерүләре мөмкин, диде.

Иптәш Сталин ул вакытта ук инде болай дип күрсәткән иде: авыл хуҗалыгы артеле **„колхоз хәрәкәтенең төп буыны** булып тора, чөнки ул бөртекле ашлык проблемасын хәл итүнең максатка иң яраклы формасы. Бөртекле ашлык проблемасы исә **бөтен авыл хуҗалыгы системасында төп буын** булып тора, чөнки аны хәл итми торып (вак һәм эре) терлекчелек проблемасын да, промышленность өчен төп чималны бирүче техник һәм специаль культуралар проблемасын да хәл итү мөмкин түгел. Менә ни өчен авыл хуҗалыгы артеле хәзерге моментта колхоз хәрәкәте системасында төп буын булып тора“. („Ленинизм мәсьәләләре“, бит 370).

Иптәш Сталинның „уңышлардан баш әйләнү“ исемле мәкаләсендә бирелгән положениеләр һәм бурычлар ВКП(б) Үзәк Комитетының „Колхоз хәрәкәтендә партия юлын бозуларга каршы көрәш турында“ 1930 нчы елның 15 нче март карарына нигез итеп алындылар.

Иптәш Сталинның 1930 нчы ел, 3 нче апрельдә иглан ителгән икенче бер мәкаләсе—„Колхозчы иптәшләргә җавап“ исемле мәкаләсе дә шушы тарихи документларга нык бәйләнгән. Бу мәкаләсендә иптәш Сталин, крестьяннәр мәсьәләсендәге ялгышларның тамырын һәм колхоз хәрәкәтендәге төп ялгышларны күрсәтеп, авылда сыйнфи көрәш законнарын гадәттән тыш тирәнлек һәм ачыклык белән аңлатып бирде.

Сталин җитәкчелеге нәтиҗәсендә партиябез колхоз төзелешендәге ялгышларны һәм бөгелешләрне кыска срокта бетерә алды. Кулакларның, троцкичыларның, бухаринчыларның котырынып каршылык күрсәтүләрен җиңеп, һәр төрле „сул“ бөгелешчеләрнең куркынычлы бозуларын бетереп, партия колхоз хәрәкәтенең тагын да куәтле рәвештә үсүе өчен нык нигез булдыра алды. Озак та үтми, моның нәтиҗәләре күренә башлады.

1930 нчы елның 1 нче маена төп бөртекле ашлык районнарында крестьян хуҗалыкларын коллективлаштыру 40—50 процентка җитте, ә 1931 нче елны инде бу районнарда крестьян хуҗалыкларының 80 проценттан артыгракы, СССР ның башка районнарында 50 процент чамасы колхозларга берләштерелде. Бу чорда инде колхозлар һәм совхозлар илебездәге бөтен чәчүлек мәйданының өчтән ике өлешен чәчтеләр. Ә беренче бишьеллык тәмамланганда СССР инде дөньяда иң эре авыл хуҗалыгы иле булып әверелде.

Иптәш Сталин җитәкчелегендә партия социалистик революциянең властьне яулап алудан соң булган иң кыен бурычын—вак крестьян хуҗалыкларын социализм юлына күчерү бурычын, иң күп санлы эксплоататорлар сыйнфы булган кулакларны бетерү бурычын хәл итте.

Бу бөек җиңүгә партиябез һәм совет халкы барыннан да элек иптәш Сталинның даһиларча җитәкчелеге аркасында, аның фәнни яктан алдан күрә белүе аркасында, СССР да социалистик төзелеш тәҗрибәсендә бөек Маркс—Энгельс—Ленин таглиматын аның тагын да эшләве һәм киңәйтүе аркасында ирештеләр.

Лениннең кооператив планына таянып, иптәш Сталин авыл хуҗалыгын коллективлаштыру теориясен, авылны социалистик нигездә үзгәртеп коруның конкрет юлларын һәм формаларын даһиларча эшләп чыгарды. Ул колхозлар эше тәҗрибәләрен даһиларча осталык белән туплады һәм авылда социализм төзелешенең нигезләрен Авыл Хуҗалыгы Артеленең Үрнәк Уставында эшләде. Болар барсы да марксизм-ленинизм теориясенә гаят зур яңа хәзинә булдылар.

Партиянең тарихи XVIII нче съездында, СССР ның авыл хуҗалыгы үсешенә йомгаклар ясап, иптәш Сталин, илебездә хәзер колхозлар тәмам ныгыдылар, ә хуҗалыкның социалистик системасы игенчелегебездә бердән-бер форма булып әверелде диде. Хәзер балык тоту һәм промысло колхозларын санамаганда, 18 миллион 800 меңнән артык крестьян хуҗалыгы колхозларга берләшкән.

Совет крестьяннәренең тарихи җиңүләре иптәш Сталин исеменә аерылгысыз бәйләнгән. Бу җиңүләр иптәш Сталинның, партиябез Үзәк Комитетының һәм Совет хөкүмәтенең СССР халыкларын коммунизмның тулы тантанасы юлы белән даһиларча алып барганлыкларын һәм алып баруларын ышандырырлык итеп күрсәтәләр.

Н. Фомин.

Чит илләрдә

ҺИНДСТАНДА ХӘЛНЕҢ КИСКЕНЛӘШҮЕ

НЬЮ-ЙОРК, 1 март. (ТАСС). Юнайтед Прессның хәбәр итүенә караганда, Һиндстан милли конгресының башкарма комитеты Англиянең Һиндстанга хәзер үк бәйсезлек бирүдән баш тартуына каршы протест йөзеннән властьларга буйсынмау кампаниясе үткәрүне яхшы дип тапкан. Башкарма комитет кампанияне кайчан һәм ничек башлауны хәл итү өчен аның башлануын берничә көнгә кичектерү турында Гандиның тәкъдимен кабул иткән.

Башкарма комитет конгресс членнарын Англиянең Һиндстан сугышучы ил дип белдерүенә каршы протест белдерергә һәм „Англия империализмы интересларында алып барыла торган“ Европа сугышыннан читтә торырга чакырган.

Конгрессның лидерлары Неру һәм Патель Һиндстанның бәйсезлеге өчен хәзердән үк көрәш башларга чакыралар.

ЛОНДОН, 1 март. (ТАСС). Рейтерның хәбәр итүенә караганда, Һиндстан милли конгрессының башкарма комитеты бюросы Һиндстанның максаты—тулы бәйсезлеккә ирешү дип янадан резолюция кабул иткән. Резолюциядә болай диелә:

„Британия империализмы кулында булганда Һиндстанга азатлык тәэмин ителмәячәк. Империя системасында доминион статусы яки нинди булса да башка төрле статус Һиндстан өчен һич тә кабул ителерлек түгел һәм ул бөек халыкның дәрәҗәсенә туры килми. Һинд халкы үз конституциясен бары тик үзе генә төзи ала һәм дөньядагы башка илләр белән мөнәсәбәтләр турындагы мәсьәләне ул гомуми сайлау хокукы нигезендә сайланган учредительный собраниедә хәл итә алачак“.

Резолюциянең кереш өлешендә Англия хөкүмәте исеменнән ясалган соңгы белдерүләрнең Англиянең сугышны империалистик теләк белән алып баруын күрсәткәнлеге әйтелә. Мондый хәлләрдә конгресс сугышны яклый алмый һәм шунлыктан Англия өчен көрәштә Һиндстан гаскәрләрен файдалануга каршы һәм сугыш теләкләре белән Һиндстаннан кешеләр һәм материаллар җибәрүгә каршы протест белдерә.

КАШЕН ТУРЫНДА ФРАНЦИЯ СЕНАТЫНЫҢ КАРАРЫ

ПАРИЖ, 1 март. (ТАСС). „Демократик“ Франциядә террор көннән-көн көчәя. Франция халкының чын вәкилләре—коммунист депутатлар хокукларыннан мәхрум ителеп хәрби кыр судларына бирелделәр.

Кичәге көнгә кадәр Франция парламентында бер коммунист—сенатор Марсель Кашен бар иде әле. Кашенның „эшен“ тикшерү өчен сенат махсус комиссия төзеде. Комиссиянең утырышында Кашен болай диде: „Мин халык теләге белән сайландым һәм маглүм бер политиканы үткәрү өчен сенатка делегат итеп җибәрелдем. Мин үземнең электәге эшләремә турылыклы булып калам. Мин элекке позициямдә калам“.

Гаваснын хәбәр итүенә караганда, кичә сенат Кашенны сенаторлык хокукларыннан мәхрум итәргә карар биргән.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә Наньниннан төньяктарак сугышлар дәвам итә. Япон гаскәрләре авыр артиллерия һәм авиация ярдәме белән 25 нче февральдә Наньнин—Биньян шоссесендә Саньтян районында кытай позицияләренә каршы яңадан һөҗүм ясарга маташтылар. Ләкин японнар элекке позицияләренә алып ташландылар.

Кантоннан көнчыгыштарак районда 23 нче февральдә кытай партизаннары Чжашаньгә атака ясадылар. Шул вакытта алар 200 дән артык винтовка кулга төшерделәр һәм японнар иярченен—өяз начальнигын пленгә алдылар. Кытай партизаннары 23 нче февраль төнендә Кантонга бәреп кереп, анда японнарның авиация ремонты мастерскойларын яндырдылар. 27 нче февральдә кытай партизаннары отряды Кантоннан көньякта Синьхойга үтеп керделәр һәм анда японнарның берничә казармаларын яндырдылар.

Гуандун провинциясендә Сватоудан төньяктарак кытай партизаннары 28 нче февральдә Дэнхайны алдылар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Кытай гаскәрләре 22 нче февральдә Хэнань провинциясенең көньяк өлешендә Синьян шәһәренә бәреп керделәр. Бөтен төн буена дәвам иткән сугыштан соң кытайлар шәһәрне ташлап чыктылар. Хәзер Синьян тирәсендә сугышлар бара. Бу секторда японнар шактый югалтуларга дучар булдылар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Суйюань провинциясенең көнбатыш өлешендә Уюань секторында сугышлар дәвам итә.

Хэбэй провинциясенең көньяк өлешендә кытай партизаннары халык ярдәме белән японнарның юлларын җимерделәр. Японнарга стена белән чолгап алынган шәһәрләрдә ныгытылу мөмкинлеге бирмәс өчен крестьяннар шәһәр стеналарын җимерәләр. Тянцзин—Пукоу һәм Бэйпин—Ханькоу тимер юллары арасында 13 шәһәрнең стенасы һәм күп кенә ныгытмалар җимерелгән.

ХРОНИКА

РСФСР Верховный Советы Президиумы иптәш **В. П. Потемкинны**, РСФСР Мәгариф Халык Комиссары итеп билгеләде.

☘

ССР Союзы Совнаркомы иптәш **В. П. Потемкинны**, башка эшкә күчүе сәбәпле, ССР Союзы чит ил эшләре наркомы урынбасары хезмәтләреннән азат итте.

☘

РСФСР Верховный Советы Президиумы иптәш **П. А. Тюркинны** үзенең соравы буенча РСФСР Мәгариф Халык Комиссары хезмәтләреннән азат итте.

Бауман районындагы 33 нче номерлы балалар бакчасында. РӘСЕМДӘ: „Чик заставасы“. Унда—Леля Заһидуллина постта.
И. С. Папков фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

8 НЧЕ МАРТ КӨНЕНӘ ХӘЗЕРЛЕК

ФӘН РАБОТНИКЛАРЫ ЙОРТЫНДА

Фән работниклары үзешчәнлек сәнгатенә зур әһәмият бирәләр. Казан Фән Работниклары йортында хор, ялгыз җыр һәм балаларның фортепиано түгәрәкләре эшләп килә. Узган елның көзендә анда симфоник оркестр да оештырылды. Оркестрда фән работникларыннан 36 кеше катнаша. Алар арасында профессорлардан Арбузов, Евлампиев, Макарский, доцент Порфирьев, композитор Столбов һәм башкалар бар.

Халыкара Коммунистик Хатын-Кызлар көне—8 нче Март уңае белән бу түгәрәкләр Вузларда һәм хәрби частьләрдә концертлар бирәләр. 8 нче Мартта Казан Дәүләт университетының актовый залында зур концерт куелачак.

МУЗЫКА УЧИЛИЩЕСЕНДӘ

Казан Музыка училищесе хезмәт иясе хатын-кызларның халыкара көне—8 нче Март бәйрәменә хәзерләнә.

Училищедә укучыларның 35 проценты кызлар. Алар арасында уку отличниклары Сорокина, Павлова, Шәмсетдинова, Сиражетдинова һәм башкалар бар. Бу иптәшләр һәм тагын бик күпләр катлаулы музыка культурасын үзләштерүдә гүзәл нәтиҗәләргә ирешәләр.

Бәйрәм көне училищедә кичә үткәрелә. Укучылар көче белән совет композиторлары әсәрләреннән концерт биреләчәк.

ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫҢ АТУ ЯРЫШЛАРЫ

Казан Укытучылар йорты, Халыкара Коммунистик Хатын-Кызлар көненә багышлап 6 нчы мартта хатын-кызларның ату ярышларын үткәрә. Ярышларда 30 га якын кеше катнашачак. Ярышларда өстен чыгучылар бүләкләнәчәк.

8 нче Март көнне шәһәр укытучыларының бәйрәм кичәсе үткәрелә. Кичәдә докладтан соң артистлар көче белән концерт биреләчәк.

Г. КАМАЛ АЛЬБОМЫ

Татгосиздатта татар драматургы Г. Камал рәсемнәреннән альбом чыгаруга хәзерлек бара. Альбомга Г. Камалның моңарчы матбугатта басылып чыккан һәм чыкмаган рәсемнәре кертелә.

Альбом чыгаруны оештыру һәм рәсемнәрне туплау артист Габдерахман Камалга тапшырылды. Альбомга шулай ук „Яшен“ журналында Г. Камал тарафыннан ясалган рәсемнәр дә кертеләчәк.

Әдәбият түгәрәге эштә

„Зеленый Дол Эшчесе“ редакциясе янындагы әдәбият түгәрәгенең күптән түгел генә чираттагы утырышы булды. Татарстанның Тел һәм әдәбият Фәнни-Тикшеренү институтының фольклор секторы работниклары катнашы белән үткәрелгән бу утырышта фольклор һәм аны җыйнау мәсьәләсе каралды.

Түгәрәк членнарының бик күбесендә төрле жанрларда фольклор материаллары барлыгы беленде һәм алар үзләре тарафыннан җыелган фольклорны институтның фольклор секторына тапшырдылар.

„Зеленый Дол Эшчесе“ редакциясендә эшләүче Талип иптәш Хәйреттинов институтка „Ивашка кызыл фуражка“ дигән бер әкият һәм кечкенә табышмаклар, җырлар тапшырды. Горький исемендәге заводның эшчесе иптәш Чебенова халыктан язылып алынган „Гайшә“ һәм „Алданган кыз“ исемле бәетләрне бирде. Культработник иптәш Гумеров „Өч дәрвиш“, „Казны кем ашаган“, „Кире хатын“ исемле әкиятләрне тапшырды.

Әдәбият түгәрәге членнары киләчәктә дә эшчеләр арасында фольклор материаллары җыячаклары турында белдерделәр.

Х. Ярми.

Студентларның фәнни түгәрәкләре

Казан Дәүләт университетында үткән ел оештырылган тарих факультеты студентлары фәнни түгәрәкләрдә якыннан торып катнашалар. Алар доцент Устюжанин һәм ассистент Понамарев җитәкчелегендә тарих фәненең күп кенә проблемалары буенча фәнни тикшеренү эшләре алып баралар. Мәсәлән, СССР тарихын өйрәнү буенча төзелгән түгәрәк членнарыннан студент иптәш Краснов мари халкы тарихын, иптәш Леваков Чувашстан тарихын, студент Бурматин Башкыртстан тарихын өйрәнү өстендә эшлиләр.

Түгәрәккә барлыгы 27 студент йөри.

Д. И.

Артельчеләр кроссы

„Древстружка“ артелендә эшләүчеләрнең чаңгы кроссы үткәрелде. Кроссга барлыгы 15 кеше катнашты. Алар „ГТО“ның беренче баскычына нормалар тапшырдылар.

Кросста беренче булып слесарь иптәш Яшин килде. Ул 3 километр дистанцияне 19 минут эчендә үтте.

Р. З.

Шахмат чемпионаты

Чемпионатның 7 нче туры зур үзгәреш китермәде. Турнирның лидеры Сайгин Косолапов белән очрашты. Партиянең хәл итүче өлешендә Косолапов, белепмебелмичәме, һич кирәксезгә үзенең ладьясын китереп бирде һәм шуннан соң Сайгин, әлбәттә, отты.

Нәҗметтиневкә каршы аклар белән уйнаган Нотариус, партияне уңышлы дәвам иттереп, үзе өчен уңайлы эндшпильгә (партиянең соңгы өлеше) күчерде. Тактада Нәҗметтиневнең аты һәм 5 пешкасына каршы Нотариусның филе һәм 6 пешкасы калды. Партия Нәҗметтинев өчен иң уңышлы дигәндә дә ничья белән генә бетәргә мөмкин иде. Нәҗметтинев соңгы йөрешләрнең берсен 20 минуттан артык уйлады һәм аның инде 10 йөрешкә бары 4 кенә минут вакты калган иде. Аның каравы, шуннан соңгы йөрешләрне ул яшен тизлеге белән диярлек ясады. Аты белән оста маневр ясап, ул, пешкалар санын тигезләп кенә калмады, хәтта королен актив уенга кертеп, Нотариусның филен тәмам көчсез хәлдә калдырды. Нотариусның короле караларның король флангысына бәреп кергәндә инде Нәҗметтинев үзенең ферзь флангысындагы пешкасын ферзьгә чыгарды һәм... Нотариус бирелде.

Катнашучылар арасында Хенкин күренекле бер уенчыга әйләнеп бара. Аның да әле, Сайгинныкы шикелле үк, бер партиядә оттырганы юк. Вельтмандер 7 нче турда Хенкинның көчле басымыннан саклана алмады һәм бирелде. Моннан элекке турда Колчуринны откан Рөстәм Кильматов бу турда Ермолин белән ничья ясады. Колчурин Виноградовны отты.

7 турдан соң Сайгинның 6 уеннан 5 очкосы, Хенкинның—5 тән 4 һәм Нәҗметтиневнең 7 дән 5 очкосы бар.

Х.

ЧАҢГЫ ПОХОДЫ

Казан шәһәренең базарлар идарәсе Столбище һәм Питрәч районнарындагы колхозларга чаңгы походы оештырды. Походта катнашучылар оборона эшләре турында һәм колхоз сәүдәсе турында „Передовик“, „Ударник“, „Красный дозор“, „Борьба“ колхозларында һәм башкаларда беседалар үткәрделәр.

1940 нчы елда Казанның колхоз базарларына продуктлар китерү турында 6 колхоз белән договорлар төзелде. Бу колхозлар 44 тонна ит, 27 мең литр сөт, 34 тонна яшелчә, 111 тонна бәрәңге, 29 мең данә йомырка һәм башка күп төрле продуктлар китерергә йөкләмә алдылар. Аерым колхозчылар тарафыннан китерелә торган продуктлар бу хисапка керми.

СССР оборонасын ныгыту заемының тиражы

11 һәм 12 нче мартта Чиләбедә СССР оборонасын ныгыту заемының 9 нчы тиражы булачак. Барлыгы 48.871.300 сумлык 299.450 отыш уйналачак. (ТАСС).

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

Фабрикадан урлаучылар. 6 нчы тегү фабрикасының агенты Захаров һәм шофер Игонин фабрикадан берничә пар балалар костюмы урлап алып чыккан вакытта, охранник Владимиров тарафыннан тотылганнар. Захаровның квартирасында да яңа чалбарлар һәм 6 нчы тегү фабрикасының клеймосы сугылган берничә кисәк мануфактура табылган. Алар социалистик милекне урлауда гаепләнеп җавапка тартылалар.

Казан җитен комбинатында 200 кубометр күләмендә

ШЛАК САТЫЛА

Комбинатның хуҗалык бүлегенә килергә. 388—1

Дәүләт Банкысының Шәһәр бүлегеннән „Мехчы“ газетасы редакциясе исеменә 26119/160 нчы счет буенча бирелгән чек кнәгәсен (057202 дән 057225 кә кадәр 24 файдаланылмаган чеклары белән) урланган булу сәбәпле гамәлдән чыккан дип санарга. 394—1

Москвадан килгән инженерлар өчен, төрле срокларга Бауман районында

БҮЛМӘЛӘР КИРӘК

Түләү килешү буенча, Бауман урамы, 70 адресы янсә 44—05 телефоны буенча теләсә нинди вакытта Новацийгә мөрәҗәгать итәргә. 387—2—1

РСФСР Сәүдә Халык Комиссариатының Казандагы өлкәара базасы „РОССНАБТОРГ“

1940 нчы ел, 1 нче январьдан

„РОСЗАГОТСНАБТОРГ“

дип яңадан исемләнде. 240—2—2

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ

Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры бинасында 3 һәм 4 нче мартта

ИРЕК

Талоннар: бүген 81, иртәгә 82. Уен 7 сәгать 30 минутта башлана.

Зур Драма театры бинасында 7 нче мартта

ЗУР КОНЦЕРТ

Талон 83. Кич 9 да башлана. Билетлар ТДАТ кассасында сатыла. Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген, 3 нче мартта, циркның ял көне. Иртәгә, 4 нче мартта, данлыклы

ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ

300 хайван һәм кошлар катнаша һәм башка күп номерлар.

РСФСР ның атказанган артисты һәм орденлы **М. ЗОЛЛОның** соңгы гастрольләренә билетлар сатыла. Уен кич 8 дә башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

3 һәм 4 нче мартта

ЛЕНИН

Талоннар: бүген 114, иртәгә 115. Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына. Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

5 нче мартта

ШӘМСЕКАМӘР

(талон 127). Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДҮРТЕНЧЕ ПЕРИСКОП
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДУСЛАР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8 һәм 10 да	ПАТРИОТ
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9-30 да.	ДОШМАН ИШЕК ТӨБЕНДӘ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	БЕТХОВИН КОНЦЕРТЫ. Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	УКЫТУЧЫ
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
КУЛЬТУРА САРАЕ 4-30, 7, 9 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ

КИРӘК:

„Динамо“ ның Республика советына ТӘҖРИБӘЛЕ МАШИНИСТКА кирәк. Чернышевский урамы, 12/20 адресы буенча килергә, яисә 34—91 телефоны буенча шалтыратырга. 316—3—3

„Урак һәм чүкеч“ заводына даими эшкә КОНСТРУКТОРЛАР, КОНСТРУКТОРЛАР БЮРОСЫ МӨДИРЕ, КОНТРОЛЬ МАСТЕРЛАР, ТЕХНОЛОГЛАР, ВАХТЕРЛАР (охранниклар), СЛЕСАРЬ-ЛЕКАЛЬЩИКЛАР, 4, 5 һәм 6 нчы разряд МОДЕЛЬЧЫЛАР, 3, 4 һәм 5 нче разряд ТОКАРЬЛАР 3, 4 һәм 5 нче разряд ШЛИФОВАЛЬЩИКЛАР. Кызыл Армия бистәсе, Клара Цеткин урамы, 10/12, заводның кадрлар бүлеге. 315—2—2

14 нче трестның Транспорт конторасына БУХГАЛТЕР-ФИНАНСИСТ ҺӘМ АЕРЫМ БАЛАНС БУЕНЧА ЭШЛӘҮ ӨЧЕН ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР. Хезмәт хакы килешү буенча. 319—3—1

Татнаркомхозның Мелиорация-Гидротехника конторасына ИНЖЕНЕРЛАРДАН: ГИДРОТЕХНИКЛАР, ТӨЗҮЧЕЛӘР, ГИДРОГЕОЛОГЛАР. ТЕХНИКЛАРДАН: ТӨЗҮЧЕЛӘР, ГИДРОТЕХНИК-ИНВЕНТАРИЗАТОРЛАР, САНТЕХНИКЛАР, КОЛЛЕКТОРЛАР, БОРАУЛАУ МАСТЕРЛАРЫ. Шунда ук ЯРДӘМЧЕ ЭШЧЕЛӘР. Казан, Кремль, 3 нче подъезд. 330—5—2

6 нчы тегү фабрикасына МАШИНАДА һәм КУЛДАН ТЕГҮЧЕ ХАТЫН-КЫЗЛАР, ДИПЛОМЛЫ КОЧЕГАРЛАР һәм куркынычсызлык техникасы буенча эшләү өчен ИНЖЕНЕР ЯКИ ТЕХНИК. Хезмәт хакы килешү буенча. Кызыл Армия бистәсе, Клара Цеткин урамы, 22, фабриканың кадрлар бүлеге. 325—2—2

Индивидуаль заказлар буенча аяк киемнәре тегү мастерскоена даими эшкә КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ ИТЕКЧЕЛӘР һәм БАШМАКЧЫЛАР. Университет урамы, 2/51. Телефон 11—48. 359—5—3

ҮСҮ ЮЛЫНДА

(БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ ДЕКАДАСЫНА КАРАТА)

Соңгы елларга чаклы бездә балалар әдәбияты артта калган тармакларның берсе булып килде.

Татар совет балалары үз язучыларын бик озак көттеләр. Ниһаять, бөек рус әдәбиятының бу тармактагы казанышларын үзләштереп, халык шагыйре Г. Тукайның бу өлкәдәге эшләрен, матур-матур шигырьләрен үрнәк итеп алып, бездә дә балалар әдәбияты язучылары килеп чыктылар. Аларның баштагы әсәрләре әдәби яктан, әлбәттә, ул чаклы югары тормыйлар иде. Арада начарлары да, балаларның сорауларына җавап бирми торганнары да булмады түгел. Ләкин, кызганычка каршы, алар турында безнең тәнкыйтчеләребез бер ни дә әйтмәделәр. Татар совет балалар әдәбиятындагы яхшы әсәрләр популярлаштырелмәде, начарлары тәнкыйть уты астына алынмады.

Еллар үтү белән татар совет балалар әдәбиятының үсеп килүче яшь кадрлары күтәрелделәр, алар матур-матур әсәрләр иҗад иттеләр.

1939 нчы елда да балалар әдәбияты язучылары җиң сызганып эшләделәр. Иптәш Г. Гобәй балалар тарафыннан яратылып укыла торган „Маякчы кызы“н бирде, шуның өстенә тагын яңа повесть һәм „Өч бөркет“ дигән пьеса язды. А. Әхмәт иптәшнең „Шикле кеше“ дигән пьесасы басылып чыкты һәм ул мәктәп сәхнәләрендә бик күп тапкырлар куелып килә. Нур Гайсин „Равиль һәм Марат“ нын һәм Маршактан уңышлы гына тәрҗемәләр бирде. Татар совет балалар әдәбиятында сәяхәт жанры өстендә эшләүче иптәш Х. Кави 1939 нчы елда „Сәяхәт“ исемле әсәрен бирде. Болардан тыш Ж. Тәрҗемановның, Хәй Вахитның, Гарәфи Хасанов һәм башка иптәшләрнең уңышлы гына әсәрләре басылып чыкты.

Татар совет балалар әдәбиятының иң артта калган участкысында—мәктәпкәчә яштәге балалар өчен әсәрләр язу өлкәсендә—1939 нчы елда өч яңа исем күренде. Әширә Кәтиеваның вакытлы матбугатта басылып килгән шигырьләре, Сафиуллинаның „Кызыл җиләкләр“ һәм Таһирова иптәшнең „Әлфия“ исемле әсәрләре бу иптәшләргә күп кенә өметләр баглата.

Татар телендә беренче тапкыр „Нәни китап“ сериясеннән 3 әсәрнең басылып чыгуы да 1939 нчы елның уңышларына керә.

Болардан тыш рус теленнән тәрҗемә итеп чыгарылган китапларны да өстәсәк, 1939 нчы елда ирешелгән уңышларыбызның зур гына икәнлеген күрәбез.

Ләкин болар гына татар совет балаларының сорауларын канәгатьләндерә алмыйлар.

1940 нчы елны балалар әдәбияты язучыларының һәрберсе яңа әсәрләр өстендә эшлиләр. Татгосиздатның яшьләр—балалар әдәбияты секторының планы белән танышкач, моны ачык күреп була. Ләкин әсәрнең исмен планга кертү белән генә тынычланырга ярамый, аларның басылып чыгуларын да тәэмин итәргә кирәк.

Яшьләр—балалар әдәбияты секторының планы җитәрлек дәрәҗәдә уйланылып төзелмәгән һәм конкретлаштырылмаган. План—булганны теркәүдән генә гыйбарәт дип әйтерлек. Һәр язучыдан „1940 нчы ел өчен син нәрсә бирәсең?“—дип сораганнар да, язучы әсәрнең исмен, күләмен әйткәч, шуны планга язганнар да куйганнар. Ул әсәрнең нинди тормыштан алынып язылуын, темасы нәрсә икәнлеген сектор җитәкчеләре бөтенләй белмиләр.

Бездә татар телендә фәнни-фантастик әсәрләр һәм фән-техника буенча популяр китаплар юк дип әйтерлек. Татгосиздат работниклары бу китапларның Детиздатта басылып чыгуын көтәләр. Детиздат чыгарган китапларны басу яхшы һәм кирәкле эш. Ләкин тырышканда шушы ук эшне безнең үзебездә дә оештырып булыр иде бит. Монда Татгосиздатның кадрлар белән эш итә белмәве бик ачык күренеп тора. Бар нәрсәне дә кадрлар хәл иткәнен истән чыгармаска кирәк. Издательство һәм Татарстан Совет Язучылары Союзы балалар әдәбияты өлкәсендә эшләүче кадрларның санын үстерү буенча конкрет чаралар күрергә тиешләр.

Татарстанда фәнни көчләр шактый күп. Бары тик аларны оештыра һәм алардан яздыра белергә генә кирәк.

Педагогларны да бу эшкә тартырга бик вакыт. Укытучы Гариф Богданов иптәш табигать фәне буенча татар телендә матур-матур китаплар язган кеше. Бер вакытны аның 7—8 әсәре басылып та чыкты. Тәҗрибәсе булуга да карамастан, бу иптәш ни өчендер хәзер балалар әдәбиятына тартылмый.

Касыйм Шамиль иптәш балалар өчен „Тычканга үлем, мәчегә көлке“ исемле яхшы гына комедия язган. Аның тагын да шундый әсәрләре бар. Ләкин яшьләр—балалар әдәбияты секторына ул үзе килеп әйтмәгәч, аның әсәрләре планга кертелмәгәннәр.

Ниһаять, өлкән язучылар белән эшли белмәүне ничек дип аңларга кирәк?! Өлкән язучылар үзләренең әсәрләре белән планда бик аз катнашалар. Шәриф Камал, Т. Гыйззәт, Маннур, Шамов, Муса Җәлил, Разин, Гариф Галиев әсәрләре бөтенләй юк. Дөрес, бу иптәшләр шушындый әһәмиятле эшкә—балаларга әсәрләр язуга үзләре дә салкын карыйлар. Алар күбесенчә „вакыт җитмәүне“ сылтау итеп күрсәтәләр. М. Әмир, Н. Баян, Н. Исәнбәт кебек иптәшләр вакыт табалар ич. Н. Исәнбәт иптәшнең „Балалар фольклоры“ исемле җыентыгы гыйлми яктан зур әһәмияткә ия. Аны бастырып чыгаруны ашыктырырга кирәк. М. Әмир иптәшнең „Батыр исемле малай турында хикәяләр“ исемле әсәре татар совет балалар әдәбиятының күренекле әсәрләреннән берсе булачак.

Тугандаш республикалардагы балалар әдәбияты язучыларының әсәрләренә планда бөтенләй урын бирелмәгән.

Бездә бер-ике ел гына элек басылган әсәрләрне кабат басып чыгару кебек фактлар да юк түгел. Мәсәлән, Ф. Конның „Безнең амнистия“ сы, (ул бер ел элек кенә башка исем белән басылган иде), В. Биянкинның „Урмандагы өйчекләр“ исемле әсәре. Без, билгеле, яхшы әсәрләрне кабат басуга каршы түгелбез. Ләкин әсәрләр таралып бетми торып аны кабат бастыру нигә кирәк?

Татар совет балалар әдәбиятында ике зур кимчелек күзгә ташлана. Аның берсе—зур темаларга тотынмау, аларны читләтеп үтәргә тырышу булса, икенчесе—жанр ягыннан чикләнү.

1940 нчы елда идея һәм художество ягыннан яхшы сыйфатлы әсәрләр бирү өчен безнең барыбызга да, бигрәк тә балалар әдәбияты язучыларына, укырга, гомуми культурабызны арттырырга, кешелек дөньясы даһилары Маркс, Ленин, Сталинның бөек тагылиматлары белән коралланырга кирәк.

Пролетариатның бөек язучысы Максим Горький: „Балаларны укытуның кирәкле эш икәнен әйтү белән бергә, безгә үзебезгә дә балалардан өйрәнүнең бик файдалы икәнлеген аңларга кирәк“—дигән иде. Безгә моны да истән чыгармаска кирәк. Балалар белән күбрәк аралашырга, мәктәпләрдә, пионер отрядларында ешрак булырга кирәк.

А. Алиш.

Җаваплы редактор урынбасары **И. ҮЗБЕКОВ.**

Зам. ответ. редактора **И. УЗБЕКОВ.**

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР № А — 258 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 840.